УДК 82.091

*Зәйнәп Максудова,*
*Шакир Абилов*

# ШАГЫЙРЬ СӨЛӘЙМАН САКСИНИ ҺӘМ АНЫҢ «ДАСТАНЕ МОГҖИЗАТ» ӘСӘРЕ (XII йөз)

Вниманию читателей предлагается архивная публикация совместной статьи татарских филологов позднесоветской поры – З.Г. Максудовой и Ш.Ш. Абилова, посвященной подробному изучению поэтического наследия Сулеймана ас-Саксини (XII в.). Авторы статьи, подготовленной к печати еще весной 1969 г., доказывают принадлежность сочинения «Дастан о [пророческих] чудесах» ас-Саксини и приводят скрупулезный анализ языка этого произведения. Важно отметить, что по мысли одного из авторов, З.Г. Максудовой, главной целью ас-Саксини в написании этого сочинения было описание образа идеальной личности мусульманина. Выводы, сделанные нашими старшими коллегами еще полвека назад, не потеряли своей актуальности и будут интересны современным исследователям.
**Ключевые слова:** исламская поэзия, Сулейман ас-Саксини, татарская филология, исламские рукописи, Саксин.

This is an archival publication of the article co-authored by the Tatar philologists of late Socialist era, namely Zainap Maksudova and Shakir Abilov. In their article, prepared already in spring 1969, the authors meticulously study the poetic legacy of the 12th century scholar Sulayman al-Saqsini. They argue that this scholar authored a work entitled *Dastan-i mu'jizat* and provide a detailed philological analysis of the text. Notably, one of the authors, Zainap Maksudova, claimed that the main goal of al-Saqsini in composing this poetical work was to describe an ideal type of Muslim personality. Observations made by these authors more than a half-century ago are still valuable and relevant for the ongoing research.
**Keywords:** Muslim poetry, Sulayman al-Saqsini, Tatar philology, Islamic manuscripts, Саксин.

## Кереш сүз[1]

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән фәнни мәкалә татар әдәбиятын өйрәнү тарихын яктырта. Соңгы гасырның 60 нчы еллары ахырында ук басмага әзерләнгән, әмма кулъязма рәвешендә генә сакланып калган мәкалә үз укучысын ярты гасыр дәвамында көтәргә мәҗбүр итте. Бүгенге көндә борынгы татар әдәбиятының күп кенә сәхифәләре дә бер серле пәрдә артында яшеренеп, аңа багышланган фәнни күзәтүләрнең зур өлеше архивларда, шәхси кулларда кала бирә. Чыннан да, борынгы тарихка

[1] This research is supported by the ERC Starting Grant «MIND: The Muslim Individual in Imperial and Soviet Russia». Эш барышында ярдәм күрсәткән Рәмзия ханым Абзаловага һәм Илһам абый Гомәровка ихлас рәхмәтләремне белдерәм.

ачыклык кертер өчен, беренче чиратта, безнең «хөрмәтле сәләфләребез»-нең эшләгәннәрен барлау зарур, чөнки төрле фәнни тармакларыбызның үз бай тарихы бар. Аны тирәнтән өйрәнмичә, әлбәттә, фән үсешен алга җибәрү авыр. Шуңа күрә, коллегаларыбыз күрсәткән юл белән[1] без дә фән тарихын өйрәнүгә үз өлешебезне кертергә тырышыйк[2].

Зәйнәп ханым Максудова (1897–1980) һәм Шакир ага Абилов (1915–2003) тарафыннан язылган күләмле мәкалә Татарстан Республикасы Милли музеенда – З. Максудова фондында саклана. Башка материаллардан аермалы буларак, әлеге мәкалә басмага тулаем әзер диярлек иде. Аның ни өчен үз вакытында дөнья күрмәве билгесез, ләкин мәкаләнең монографик характерда булуын һәм «торгынлык чорында» язылуын истән чыгармыйк. Хәер, шактый вакыт билгесезлек шәүләсе астында яткан фәнни күзәтүләрнең югары сыйфаты һич үзгәрмәгән, хәтта киресенчә: бу көннәрдә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан басмага әзерләнә торган Сөләйман Саксини әсәрләре җыентыгына[3] урынлы бер өстәмә һәм татар галимнәренең электән үк бу темага әһәмият бирүләренә бер дәлил буларак, мәкалә үз вазифасын тиешенчә үти.

Тәкъдим ителгән мәкаләнең төп фикере шунда ки, авторлар, махсус эзләнүләр нәтиҗәсендә, күптән билгеле булган «Дастаны Могҗизат» исемле шигъри әсәрне мәшһүр дин галиме Сөләйман Саксинигә нисбәтлиләр. Әлбәттә, бу мәсьәләдә фәндә төрле фикер булырга мөмкин, әмма хөрмәтле галимнәребез ясаган күзәтүләр һәм филологик анализ, һичшиксез, игътибарга лаек. Бигрәк тә шуны искәртергә кирәк: авторларның татар кульязма традициясен тирәнтен белүләре, филологик принципларга тугры булулары һәркемгә ачык билгеле. Нәкъ менә шушы филологик профессиональлек ягыннан фәнни сәләфләребезнең мирасы безнең өчен аеруча кадерле. Шулай да, совет чорында киң таралган кайбер фәнни карашларның тәэсирен дә искәртик. Мәсәлән, бу һәм башка мәкаләләрдә Зәйнәп ханым Максудованың борынгы татар әдәбияты тарихында секуляр мотивларны эзләвен, катлаулар көрәше контекстына кертүен, европоцентрик карашларны кабул итүен – боларның барысын да үз чорының сәяси мохите белән аңлатып була. Чынлыкта исә, Зәйнәп ханымның дингә дә, татар әдәбияты дөньясына да шәхси карашы күпкә катлаулырак һәм нечкәрәк иде[4], тик бу нечкәлекләрне шул вакыт таләпләре ачык күрсәтергә ирек бирмәде.

---

[1] Мәүла Колый поэмалары: «Берекқәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2011. Б. 3; *Госманов М.Г.* Хәтер мизгелләре. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019.

[2] *Бостанов Ә.* Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы // Фәнни Татарстан. 2015. № 1. Б. 112–126; *Альберт Фәтхи.* Габделҗәббар Кандалый шигырьләре җыентыгы // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 151–170; *Альберт Фәтхи.* Үткән гасырларның шигъри сәхифәләре // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 149–166.

[3] *Гомәров И.Г.* Татар иляһият гыйлеме традицияләренең билгесез чыганаклары: Сөләйман бине Дауд әс-Суваринең «Зөһрәт әр-рийаз...» әсәре // Фәнни Татарстан. 2019. № 4. Б. 50–54.

[4] Бу турыда тулырак: *Бустанов А.К.* Библиотека Зайнап Максудовой. М.: ИД Марджани, 2019.

Зәйнәп ханым Максудова фондында Сөләйман Саксини белән бәйле тагын биш саклау берәмлеге билгеле. Аларның берсе – галимнең «Зөһрәт әр-рийаз» әсәренең татарчага тәрҗемәсеннән өзекләр (гарәп графикасында)[1]. Икенчесен Максудова тарафыннан төзелеп, «Сөләйман бине Дауд ның тел байлыгы» дип исемләнгән карточкалар тәшкил итә[2]. Өченче материал фәнни мәкалә өчен әзерләнгән күзәтүләрне, чыганаклардан күчермәләрне һәм кайбер тәрҗемәләрне үз эченә ала[3]. Дүртенчесе – 1968 елда машинкада җыелган 56 битлек мәкалә варианты. Анда Зәйнәп Максудова тарафыннан ясалган шактый гына өстәмәләр һәм үзгәртүләр очрый, аларның барысы да гарәп хәрефләре белән язылган[4]. Бишенче һәм соңгы саклау берәмлеге аерым бер дәфтәрдән гыйбарәт. Ул – «Сөләйман бине Дауд Саксини әсәрләре: күчермәләр, тәрҗемәләр. Җыючы: Зәйнәп Максудова» дип исемләнгән (кызганыч, материалның җыю датасы куелмаган). Бу саклау берәмлеге аеруча әһәмиятле, чөнки монда галимәнең фәнни планнарының никадәр киң һәм җитди икәнлеге күренә. Аңлавыбызча, ул Саксини иҗатына багышланган китап әзерләргә тели һәм аның эчтәлеген түбәндәгечә тасвирлый:

1) «Тәрҗемәи хәле. Мосанниф хакында төрле галимнәрнең хәбәрләре буенча.

2) Саксин шәһәре хакында кыскача белешмә.

3) «Дастане Могҗизат» («Сир ән-Нәби») китабы хакында мәгълүмат:

а) тышкы тәүсифе,

б) эчтәлеге,

в) теле, грамматик төзелеше, сүзлек составы, стиле, сүз бизәкләре, тасвирлау чаралары,

г) шигырь техникасы – вәзеннәре, кафияләре.

4) Кол Галинең «Йосыф Зөләйха»сы, нәмәгълүм шагыйрьнең «Кисекбаш»ы, Өмми Кәмал диваны һәм кабер ташларындагы язмалар белән чагыштырма.

5) Сөләйман бине Дауднын табылган башка әсәрләре.

6) Нәтиҗә – Сөләйман бине Дауд Саксини Идел буе төркиләренең XII йөз галиме, әдибе, шагыйре. Аның әсәрләре халык арасында сөелеп укылган, күп таралган»[5].

Әгәр дә дәфтәрнең эчтәлегенә күз салсак, бу планның зур өлеше монографик рәвештә чынга ашырылган. Дәфтәрнең язмалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 3а–11б кәгазьдә: Саксининең кыскача биографиясе һәм шигырьләре турында фикерләр; 19а–40а кәгазьдә: Казембек чыгарган «Дастане Могҗизат» китабының тулы күчермәсе; 41а, 42а, б кәгазьдә: «XII йөз Болгар-Саксин теле һәм әдәбияты мирасы, Таҗел-ислам шәех Сөләйман б. Дауд Саксини әл-Болгари әсәрләреннән «Дастане Могҗизат»

[1] НМ РТ 18369-353.
[2] НМ РТ 18369-354.
[3] НМ РТ 18369-356.
[4] НМ РТ 18369-355.
[5] НМ РТ 18369-358, л. 1б.

хакында»; 43а–45а кәгазьдә: «Әсәрнең назыймы хакында биографик белешмәләр»; 46а–49б кәгазьдә: «Сөләйман б. Дауднын дастаннарында кулланган аерым сүзләр-исемнәр»; 61б–71б кәгазьдә: сүз байлыгы (җәдвәлдә); 76б, 91а–93а кәгазьдә: «Сөләйман Саксини китабын төзүдә максаты нәрсәдә икән?»; 95б–96а кәгазьдә: «Саксин шәһәре хакында тарихи хәбәрләр»; 96б–97б кәгазьдә: «Сөләйман Саксининың әсәрләрендә имля нигезләре»; 98а–99а кәгазьдә: «Файдаланган әдәбият шәрык телләрендә, гарәп, фарсы, төрки». Исемлектән күренгәнчә, түбәндәге мәкалә – бик җитди һәм дәвамлы алып барылган тикшеренүләр нәтиҗәсе. «Фәнни Татарстан»ның алдагы саннарында бу фондтагы материалларның башка өлешләре дә дөнья күрер дип өметләнәбез.

*Әлфрид Бостанов*

Идел буе Болгар дәүләте культурасы мең еллар буена татар культурасының нигезе булып хисаплана. Асылда болгар-кыпчак булган, соңыннан билгеле тарихи шартларда башка исем белән аталып киткән Идел-Урал татарлары үзләренең гореф-гадәтләренең, гаилә-көнкүрештәге һәм идарә итүдәге тәҗрибәләренең, әдәбият һәм гомумкультура традицияләренең башлангычын һәрвакыт болгар дәвереннән хисаплады, шуннан үзенә рухи азык алды.

Шул дәвернең әдәби мирасы – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы («Йосыф китабы» яисә, соңгырак вакытта кабул ителгәнчә, «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы) татар халкын менә 737 ел буенча сокландырып килә. «Кыйссаи Йосыф» болгар-татар халкының культура үсеше тарихы, яшәеше белән аерылгысыз бәйләнгән. Азәрбайҗан әдәбиятын – Низамидан, Иранныкын – Фирдәүсидән, таҗикныкын – Рудаки, Җамидан, үзбәкнекен –Нәваидан, төрекмәннекен –Мәхтүмкулидән, грузинныкын Руставелидан башка күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек, болгар-татар әдәбияты турында да Кол Галинең «Йосыф китабы»ннан башка фикер йөртү мөмкин түгел. Ул болгар-татар шагыйрьләренә шулчаклы йогынты ясаган ки, аның назымында – шигъри үрнәгендә дистәләрчә әсәрләр иҗат ителгән. Шулай итеп, «Кыйссаи Йосыф» болгар-татар поэзиясенең һәм әдәбиятының үсү юлында үзе бер зур тарихи чорны тәшкил иткән гүзәл ядкяр булып тора.

Болгарның алга киткән, культуралы дәүләтләрдән булганлыгы турында күп язылган. X йөздә яшәгән тарихчылардан Ибне Рустә һәм әл-Бәлхи болгарларның игенчелек белән шөгыльләнеп, бодай, арпа, тары һ.б. шундый ашлыкларны игүләре турында сөйләп, аларның җамигъ мәчетле һәм мәдрәсәле Болгар һәм Сувар шикелле шәһәрләре булганлыкны язалар.

Гарәбстаннан һәм Харәземнән Болгарга дин генә түгел, культура, әдәбият та килгән. Ислам дөньясында һәр мәчетнең аерылгысыз юлдашы булып саналган мәктәп һәм мәдрәсәләрдә, дин дәресләре генә түгел, дөньяви белемнәр дә өйрәтелгән. Акча сугу ягыннан да Болгар Көнчыгыш Европада беренче шәһәрләрдән санала [Бартольд, 1963].

Асылда утраклыкта яшәү һәм игенчелек белән шөгыльләнү Болгарда хуҗалык ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен һөнәрчелекне тудырган: моның нәтиҗәсе буларак, иҗтимагый хезмәт бүленеше процессы болгарларда шәһәрләрнең тууына китергән. Болгарлар «кою ысулы белән корыч ала белгәннәр һәм аларның металл эшкәртеп, яхшы сыйфатлы әйберләр әзерләүче югары квалификацияле осталары булган» [Хлебникова, с. 8]. Бу хәл Болгар дәүләтендә, һөнәрчелекнең игенчелектән аерылып, мөстәкыйль рәвештә киң юл ала барганлыгы һәм иҗтимагый хезмәт бүленешенең шактый югары дәрәҗәгә ирешкәнлеге хакында сөйли.

Б.Д. Греков та: X гасырда болгарларда, җәй көннәре җәйләүләргә чыгуларына карамастан, шәһәрләр булган, аларда һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр даими яшәгәннәр, дип яза [Греков, с. 569]. Һөнәрчелекнең киңәюенә һәм шәһәрләрнең тиз үсүенә Болгарның халыкара сәүдә, культура мөнәсәбәтләренең олы юлы – Идел буенда урнашуы да зур ярдәм иткән, һәм X гасырлардан алып, Болгар халыкара зур базарга әверелгән [Смирнов, с. 39]. Бу – Болгарның экономика һәм культура ягыннан үсүенә зур этәргеч ясаган. Гарәп, һинд, фарсы, Урта Азия әдәбиятлары аша болгарлар борынгы юнан (грек) һәм Рим философиясе, культурасы белән дә танышканнар. Әнә шул культураларны үзенә кабул итәрлек социаль җирлек Болгар дәүләтендә җитешә алган була.

Биредә Болгар дәүләтендәге шәһәр культурасы мәсьәләсенә махсус тукталуыбызның сәбәбе шунда: чөнки бу «Йосыф китабы» авторы Галидән нәкъ бер гасыр алда, Болгар илендә иҗат иткән галим, әдип һәм шагыйрь Сөләйман Саксинины һәм аның әсәрләрен аңлау өчен дә кирәк.

«Идел болгарлары, – дип яза А.П. Смирнов, – Урта гасырларда Европадагы алдынгы дәүләтләр рәтенә керә һәм ул Киев, Бөек Новгород кебек мәркәзләр белән бер сафка куярлык» [Смирнов, с. 39]. Шундый культура дәрәҗәсенә ирешкән Болгарда шул заманга карата мөселман дөньясында билгеле фәннәрнең булуы, галимнәр һәм әдипләрнең яшәве, тарих, философия, хокук – юриспруденция һәм әхлак – мораль буенча трактатлар төзелүе, рисаләләр, хикәяләр һәм зур күләмле поэтик әсәрләр иҗат ителүе бер дә гаҗәп түгел. Моны Болгар дәүләте ирешкән иҗтимагый хезмәт бүленеше, материаль тормышны җитештерүнең югары ысулы тудырган. Чөнки: «Материаль тормышны җитештерү ысулы гомумән, тормышның социаль, сәяси һәм рухи процессларын билгели» [Маркс, 1949, с. 352]. Югары шәһәр культурасына ирешкән Болгарда язма әдәбият та иртә барлыкка килгән. Болгар үзенең атаклы галимнәре белән таныш булган.

Болгар-татар тарихына багышланган китапларда күбрәк галим Ягкуб бине Ногман телгә алына. Ул Болгарда казый булып торган һәм «Болгар тарихы» дигән әсәр дә язган. Испан гарәбе сәяхәтче Әбү Хәмид әл-Гарнатый 1135–1136 елларда Болгарда торган вакытында Ягкуб бине Ногман белән күп очрашкан һәм аннан Болгар тарихына

караган мәгълүматлар да алган. Ш. Мәрҗани Ягкуб бине Ногманнан бер гасыр алдарак яшәгән Хуҗа Әхмәт Болгари, казый Әбел-Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари кебек галимнәр турында да яза һәм Әхмәт Болгари Газнәвиләр династиясенең башы, солтан Мәхмүд бине Сүбүктәгинның остазы – укытучысы, шәехе – өйрәтүчесе булган, ди. Ул соңгысының, ягъни Хәмид Болгариның һиҗри VI гасыр чикләрендә, ягъни милади XII гасыр башларында исән булганлыгын хәбәр итә. Шушы болгар казые, галим Әбел-Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари «Дастане Могҗизат» әсәрен язган Сөләйман Саксининың да остазы булган [Мәрҗани, б. 78–79].

**Сөләйман Саксини**

Исемен Сөләйман дип куйган һәм Идел буе төрки-татарларда борынгы вакытлардан алып хәзерге көнгә кадәр укылып килгән «Дастане Могҗизат» әсәрен саксинлыларга мөрәҗәгать итеп язган шагыйрь кем, кайчан һәм кайда яшәгән?

Саксини һәм Сувари белән нисбәтле Сөләйман бине Дауд исемле шагыйрь Урта гасырлар болгар-татар әдәбиятыннан тыш башка төрки әдәбиятлар тарихында билгеле түгел.

Ш. Мәрҗани болгар галимнәре турында язганда, Сөләйман бине Дауд Саксинига тукталып, кайбер мәгълүматлар да бирә. Хаҗи Хәлфә исә үзенең энциклопедиясендә бу галим һәм язучыны Сөләйман бине Дауд Сувари дип күрсәтә [Хаҗи Хәлфә, б. 551].

Идел буе төрки, болгар-татар поэзиясе тарихында зур урын тоткан «Дастане Могҗизат» әсәренең авторы булган, үзен саксинлылар белән бәйләнешле хисаплаган шагыйрь Сөләйман Ш. Мәрҗанидә «Сөләйман бине Дауд Саксини» дип, ә Хаҗи Хәлфәдә «Сөләйман бине Дауд Сувари» дип күрсәтелгән.

Сөләйман Саксини турында хәбәрләр бик аз. Шулай да, безгә мәгълүм булган чыганакларга һәм әсәрләренә таянып, Сөләйман бине Дауднң шәхесе һәм заманы турында гомуми картинаны күз алдына китерергә мөмкин.

Ш. Мәрҗани Сөләйман бине Дауд Саксининың «Зөһрәт әр-рийаз» («Бакча чәчәге») исемле әсәреннән өзекләр китерә. Сөләйман шул әсәрен соңыннан 67 бабка – мәҗлескә бүлеп, аны «Зөһрәт әр-рийаз вә нөзһәтел-колубел-мираз» («Авыру күңелләрне сөендерүче бакча чәчәге») дип исемләп, һәр бүлек башында Хәмид Болгари аша хәдис риваятьләре белән, үгет-нәсыйхәт мәсьәләләре хакында фикер йөртә һәм шунда Хәмид Болгарины Шәйхел-имам (имамнар башлыгы), казый дип атап, үзенең остазы икәнлеген әйтә. Хәмид Болгари, мөселман хокуклары буенча дәрес биргәндә, үзе таянып сөйләгән әсәрләрнең авторларын да шәкертләренә җиткерә торган булган. Сөләйман бине Дауд, Болгардагы мәдрәсәләрнең берсендә дәрес алган вакыты 1120–1130 елларга туры килеп, XII йөзнең беренче яртысында иҗат иткән дип чамаларга мөмкин.

Сөләйман Саксини шул заманның таләпләренчә, ислам фикъһе-юриспруденция, Коръән тәфсире, хәдис гыйлеме, гарәп-фарсы, төрки

телләре һәм әдәбиятлары, шигырь-гаруз һәм әхлак-әдәп гыйлемнәре өйрәнеп, шул әхлак фәненең шәехе – остазы булып әверелгән. Ул Болгар, Сувар, Саксин шәһәрләрендә вагыйз-әхлак, әдәп, хокук гыйлемнәренең остазы булып хезмәт иткән һәм күп әсәрләр дә язган. Шулай итеп, без XII йөзнең урталарында, моннан 800 еллар элек яшәп иҗат иткән борынгы Идел буе төрки поэзиясе вәкиле Сөләйман Саксини белән танышабыз.

Сөләйман бине Дауднның әсәрләре таралган һәм күпләргә таныш булган. XV йөздә Хөсәен Байкара заманында Һиратта яшәгән галим һәм язучы үзенең «Төхфәтел-Мөлек» («Патшалар бүләге») исемле фикъһе-хокук китабында Сөләйман бине Дауднның «Зөһрәт әр-рийаз» әсәреннән өзек китергән. XVI йөз татар язучысы Нух 1592 елда язган «Бостан әл-Коддес вә Гөлстан әл-әнес» китабында «Зөһрәт әр-рийаз»дан бер хикәяне тулысынча биргән. Шәех, таҗел-имам Сөләйман бине Дауд исеме XVI–XVII йөз госманлы галиме Мөхәммәд Чукраклы-Задәнең «Алты бармак (яисә «Дәлаилен-нәбүүәт Мөхәммәди») китабында еш очрый. Автор анда Сөләйманның «Зөһрәт әр-рийаз» әсәреннән ун урында төрле күләмдә өзекләр алган.

Бөтен дөньяга билгеле булган, югарыда телгә алынган Хаҗи Хәлфә: Сөләйман бине Сувари фарсы телендә «Бәһҗәт әл-әнвар» («Чәчәкләр шатлыгы»), гарәп телендә «Зөһрәт әр-рийаз» дигән әсәрләр язган һәм аның вәгазь, әхлак, әдәп кануннарын өйрәткән бу китапларының бик мәшһүр булганлыкларын сөйли.

1813 елда Татарстанның Кавал авылында Бикмөхәммәт Бикбау углы тарафыннан язылган кульязма җыентыкта «Зөһрәт әр-рийаз»дан «Мигъраҗ» хикәясе гарәп телендә тулысынча күчерелгән. XVIII–XIX йөз галиме Мөхәммәд-Әмин Сабави 1786 елда күчереп язган «Гакыйдатес-Сөнусия» мәҗмугасында «Зөһрәт әр-рийаз» әсәреннән бер хикәяне тулысынча теркәгән.

Болардан тыш, Сөләйман Саксининың «Зөһрәт әр-рийаз» әсәре Ш. Мәрҗани кулында да булган, ул аның аерым өзекләре белән укучыларны да таныштырган. Казан галиме, тарихчы Хөсәен Әмирхан углы үзенең «Нәҗмет-тәварих» («Тарихлар йолдызы») исемле әсәрендә «Зөһрәт әр-рийаз»дан бер өзек китергән.

Китерелгән бу мисаллардан күренә ки, болгар туфрагында яшәгән Сөләйман бине Дауд Саксини Суваринең гарәп һәм фарсы телләрендә язылган әсәрләреннән «Зөһрәт әр-рийаз» һәм «Бәһҗәтел-әнвар» кебекләре Урта һәм Кече Азиядә, Идел буенда күп кешеләр тарафыннан укылган; күп галимнәр аның китапларыннан файдаланган. Сөләйманның төрки телдә язылган «Дастане Могҗизат» әсәре Идел буенда язма һәм басма килеш күп таралган булса да, татар әдәбияты белемендә, нишләптер, игътибарсыз кала килгән. Авторлардан З. Максудова тарафыннан «Дастане Могҗизат»ның борынгы кульязмасы табылуы бу әсәрне һәм аның авторы шагыйрь Сөләйманны башлап өйрәнергә этәргеч булды.

## Сөләйманның «Саксини», «Сувари» кушаматлары һәм заманы турында

Урта гасыр авторлары исемнәрен һәм иҗат иткән вакытын әсәрләренең башында яисә ахырында күрсәтә торган булганнар, кайберләре урта бер урында да, җае туры килгәндә, үзләре турында мәгълүматны кыстырганнар. «Дастане Могҗизат»та да шулай. Дастандагы 11 нче хикәяттән бер өзек алыйк. Анда шагыйрь сүзнең шигъри көче хакында сөйли. Шигъри сүзне тыңлап ләззәтләнгәндә, тутый кош үзенең яратып ашый торган шикәрен дә онытачак ди ул[1].

Тутыййә шәкәр йимәк үгрәдәйем,[2]
Былбылә бу сүзи тәгълим идәйем[3].
Ул нотсун шәкәрен бу сүзин,[4]
Икесе дәхи бу сүзи кылсын гезин.[5]
Мостафануң мәүлүдене уксун[6],
Шәүкыйлә сәр-мәст улубән Саксун...[7]
Бу Сөләйман нәчә мәдх[8] итсүн ани,
Белең, мәддахедүр анын ул гани[9].
(II)[10]

Бу өзектә шагыйрь җылы хисләр белән тулган поэтик сүзнең көче хакында тирән дулкынланып сөйли. Шигъри әсәр бирә торган ләззәтләнү алдында татлы шикәр бер хәҗәр – таш кына. Ләкин бу өзекнең әһәмияте шунда ки, шагыйрь анда үзенең исеме – Сөләйман, халкының исеме саксинлылар булуын аңлата. Ул саксинлыларга: бу шигырьләрне укып, тәэсирләнеп, һуштан языгыз, ди. «Дастане Могҗизат»ның авторы Сөләйман булып, Саксин шәһәре һәм халкы белән бәйләнгән кеше булып чыга. Без өстә шушы бер ук кеше Ш. Мәрҗанидә «Саксини», Хаҗи Хәлфәдә исә «Сувари» (Suwari) дип язылган, дидек. Хаҗи Хәлфә кулында Сөләйманның әсәрләреннән берәрсендә аның Сувар шәһәре яисә халкы белән бәйләнгәнлеген сөйләгән, шуны күрсәткән фактлар булган дип уйларга кирәк. Шулай итеп, шагыйрь Сөләйман бине Дауд Саксини – Сувари дип аталган була.

Югарыда Сөләйман бине Дауднын Болгар казыйсы, галим Хәмид бине Идрис әл-Болгаридан дәрес алганлыгы әйтелде. Димәк, Сөләйман Болгарда укып белем алган, шулай ук әсәреннән һәм

---

[1] «Я»ның сүздә «йа»мы, «йә»ме икәнлеген күрсәтү өчен, урыны белән «йа» һәм «йә» язылды. Кыска «уау» «у-ү» хәрефләре аша бирелде. Дастандагы сүзләрнең язылу формаларын сакларга тырышылды.

[2] Юлның мәгънәсе: Тутыйга шикәр ашауны өйрәтим.

[3] Тәгълим идәем – белем бирим.

[4] Юлның мәгънәсе: бу сүз белән ул шикәрен онытсын.

[5] Кылсын гезин – сайлап алсын.

[6] Уксун – белсен, укысын, аңласын.

[7] Юлның мәгънәсе: көчле тәэсир алып Саксун (Саксин) халкы һуштан язсын.

[8] Мәдх – мактау, олылау.

[9] Гани – бай, дәүләтле. Биредә: Аллаһ.

[10] «Дастане Могҗизат»тан китерелгән юллар астында җәяләр эченә алынган саннар ничәнче «хикаять» икәнлекне күрсәтә.

китерелгән чыганаклардан күренгәнчә, Саксин – Сувар халкы арасында да яшәгән.

Шагыйрьнең «Саксини» нисбәтенә килгәндә дә, эш шулай. Саксин (Сахсин) турында күп язылган, ләкин каршылыклы фикерләр әле дә яши. Д.А. Хвольсон Ибне Рустә әсәрләрен бастырып чыгару уңае белән булган хезмәтләрендә Саксин Җаек (Урал) елгасында гына булырга тиеш дип язды [Хвольсон, с. 45, 64–65, 66 (ком., прим. 1, 8)]. Бу фикерен ныгыту өчен, ул рус елъязмасында сөйләнгәннең эчтәлеген биргән Карамзин сүзләренә таянды. Елъязмада: монгол-татарлар алдыннан саксинлыларның һәм кыпчак (половец)ларның түбәннән ашыгычлык белән югарыга күтәрелүләре (възбегоша) болгар чик сакчыларының Җаек елгасы янында монголлар белән сугышканның соңында, калганнарының Болгарга качып килүләре (прибегоша) хакында сөйләнә [ПСРЛ, с. 453]. Карамзин елъязмасында бу өзекне китергәндә: саксинлыларны, кыпчакларны һәм болгар чик сакчыларын «прибежали» (качып килделәр) дигән бер фигыль белән бирә һәм тегеләрнең барысы да бергә, бер урыннан – Җаектан качып килгәннәр булып чыга [Карамзин, с. 236]. Бартольд, Вествергның Саксин шул ук Ител шәһәре, дигән фикерен яклап, аның Идел тамагында булганлыгы мөмкинлеген әйтсә дә, бәхәсле санады [Бартольд, с. 794, 690, 588]. Заходер, Гарнатый сүзләренә таянып, Ител шәһәре егылганнан соң, Саксинны Түбән Идел башкаласы итеп таный [Заходер, с. 144].

Гарнатый сүзләренә караганда, XII гасырның урталарында, нәкъ шагыйрь Сөйләман иҗат иткән дәвердә, Иделнең түбән агымындагы Саксин күп санлы мөселман халыклы шәһәр саналып, мәчетләре дә булган [Хвольсон, с. 13–14].

Ул югары культуралы, зур сәүдә шәһәрләреннән берсе булып, читләргә көмеш, гәрәбә кебек кыйммәтле әйберләр дә чыгарган. 922 елда ук Болгар дәүләте мөстәкыйль булып, Болгар Хәзәргә бәйле булудан котылгач, Иделнең түбән агымы Болгар тәэсиренә күчә, элек хәзәр дәүләте үтәгән рольне Болгар үзе үти башлый [Бартольд, с. 690]. М. Кашгари да: «Әтел (Идел) – кыпчак илләрендәге бер елганың исеме. Ул Болгар диңгезенә коя», – дип яза [Кашгари, 1915, II, б. 70]. Бу – Болгар дәүләте көньяк чикләренең Хәзәр (Каспий) диңгезенә кадәр барып җиткәнлеген ачык сөйләүче фактлардан. Димәк, ул вакытта Саксин Болгар дәүләте тәэсирендәге шәһәр булган. М. Кашгариның: «Саксин – болгарлар янындагы бер шәһәр. Ул – шул ук Сувар», – дип язуы нигезсез түгелдер [Кашгари, 1915, I, б. 365].

Безнең уебызча, монда Саксинны шул ук Сувар итеп караганда – бу ике шәһәрдә (яисә өлкәдә) яшәгән халыкның бер ук шивәдә сөйләүче – суварлар булуы хакында сүз бара. X йөз тарихчысы әл-Мокаддисинең Болгар һәм Сувар шәһәрләре турында язганда: суварлыларның кайчандыр диңгез буена күчеп китүләре, ә соңыннан кире кайтып мөселман булганлыклары [Хвольсон, с. 84–85 (комментарий)] турында сөйләгәннәре дә Болгар суварларына карый. Саксин (Сахсин) шәһәр исеме булу белән бергә, өлкәне һәм шунда яшәгән

халыкны – кабиләне дә аңлаткан. Плано Карпини саксыларның[1] (саксинлыларның) монголларга кискен каршы торганлыклары турында яза [Плано Карпини, с. 57].

Шулай итеп, кайсы гына яктан килсәң дә, Сөләйман бине Даудның «Саксини» һәм «Сувари» дип аталуы аның болгар кешесе, Болгар дәүләтендәге галим икәнлеген күрсәтә һәм аның «Дастане Могҗизат» әсәренең теле Болгар илендәге төрки халыкларның XII йөз урталарындагы язма әдәби теле булып тора.

### Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат»ы. Әсәрнең тасвирламасы

Бу әсәр кулъязма җыентыкта, анда барысы 45 кәгазь, 90 бит. 20 б кәгазьдән «Дастане Могҗизат» башлана. Ул 25 кәгазь – 50 биттән гыйбарәт. Һәр битендә 17 бәет – 34 юл, барысы 854 бәет – 1708 шигъри юл. Башында әсәрнең исеме әйтелмәгән.

Соңгы бите төшкәнлектән, әсәрнең кайда, кайчан язылуы яисә кем тарафыннан күчерелүе анык билгеле түгел. Кәгазьнең искелегенә карап, XVI йөзнең ахырларында күчерелгән дип исәпләргә мөмкин. Рәсме хатты – нәстәгълик, иске Идел буе язуы: тел үзенчәлекләре, сүзләрнең язылышы бик борынгы. Әсәр «хикайәт» дип аталган шигъри бүлекләрдән тора, барысы 25 хикәят.

20 нче хикәяттә шагыйрь баштарак:

Бер гаҗәиб дастан дорур бу гайәт
Мостафадин белүң моны могҗизат, –

дисә, ахырдарак:

Дастане Могҗизат [бәс] улды тәмам,
Сөйләр мигъраҗендән[2] [бер] пәйам[3], –

дигән бу юллардагы «Дастане Могҗизат» сүзләре әсәрнең исеме булып чыга.

«Дастане Могҗизат» кергән кулъязма җыентык элекке Сарапул өязе Нарат авылы имамы, 1870 елларда үлгән Габдессаттар Сөендек углыннан калган әсәрләр арасыннан табыла. Бу – Сөләйман бине Дауд дастанының бердәнбер генә нөсхәсе түгел.

Дастанның төрле вакытларда күчерелгән кулъязмалары Казан, Мәскәү, Ленинград китапханәләрендә дә сакланалар. Ләкин З. Максудова кулъязмасы борынгы булуы белән кыйммәтле. «Дастане Могҗизат» тулы килеш тә, аның кисәкләре дә элек төрле елларда берничә тапкыр басылган да була. Мәсәлән, бу әсәр үткән йөзнең зур мөстәшрикъләреннән (көнчыгышны өйрәнүчеләрдән) М.А. Казембек һәм И.Н. Березинның рөхсәте белән 1849 һәм 1855 һәм аннан соңгы елларда да басылган. Элекке дәреслекләрдә, үгет-нәсыйхәт

[1] Көнбатыш тарихчыларының Иделдәге Саксин, Саксун, Сахсинны герман кабиләләре исеме сакс, саксы, саксоны белән бутап язуларын Хвольсон төзәтеп укырга тәкъдим иткән [Хвольсон, 65, комм. 3].

[2] Мигъраҗ – югарыга күтәрелү, күккә ашу. Мөхәммәднең күккә фантастик сәяхәте.

[3] Пәйам – хәбәр.

китапларында аннан төрле хикәятләр алынган, татар әдәбияты тарихында аңа ияреп әсәрләр иҗат ителгән. Шулай итеп, Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат»ы татар укучыларына якыннан таныш булып, киң таралган әсәрләрдән булган.

Басмасы белән чагыштырганда, дастанның сүз барган кулъязмасы 66 бәеткә (132 шигъри юлга) ким, әсәрнең ахырында шагыйрьнең үз хәлләре турында сөйләгән бүлекчә юк. Шунда шагыйрь үз гөнаһларын Алладан кичерүне үтенеп язганда:

Һәм бу Сөләйман фәкыйрә рәхмәт ит,
Юлдашын иман йирени җәннәт ит, –
(«Могҗизат», б. 44)[1]

дип, шагыйрь исемен тагын искә ала.

### «Дастане Могҗизат»ның эчтәлеге

Әсәр кереш өлеш белән башлана. Борынгы көнчыгыш һәм төрки әдәбиятларда урнашкан гадәт буенча, шагыйрь анда Алланы мактый. Дастанның төп өлешен башлап җибәргән беренче хикәяттә дә әле сүз шул турыда бара, Алла барлык нәрсәләрне яратучы итеп күрсәтелә. Аннан соң килгән хикәятләрнең барысы да Мөхәммәдкә: ата-анасына, Мөхәммәднең тууына, дөньяви тереклек итүенә, семья хәлләренә багышлап язылган. Соңгы хикәят аны күмәргә дип кабер янына китерү белән өзелә.

XII гасыр шагыйреннән җәмгыятьтәге социаль тормыш күренешләрен турыдан-туры сүрәтләүне көтү бик сәер булыр иде. Урта гасыр әдәбиятының үзенә генә хас яклары, үзенчәлекләре бар. Ул үзенчәлекләрнең берсе – борынгы әдәбиятларның барысында да дөньякүләм дини-мифологик сюжетларга мөрәҗәгать итү. Сөләйман Саксини да шулай итә. Ислам дөньясында Алланың илчесе, пәйгамбәре итеп күтәрелгән Мөхәммәдне башта шул яктан сурәтләсә дә, аны җир кешесе итеп карый һәм җәмгыятьтә кешеләр арасында булырга тиешле игелек, ярдәмчеллек, рәхим-шәфкатьлекне, үзенең шул турыдагы үгет-нәсыйхәтләрен, әхлак-мораль нигезләрен, гуманистик теләкләрен Мөхәммәд образы аша һәм дастанда киң урын алган лирик герой кичерешләрен чагылдырган юллар аркылы бирергә тырыша. Әсәрдә дөньяви идеяләр дини мотивлар белән бәйләнеп бара. Бу – башка әдәбиятларда да шулай. Мәсәлән, изгеләрнең («житие»ләрнең) тормышын сүрәтләү борынгы рус нәфис әдәбиятында зур урын алган. Яисә Урта гасырлардагы русның сынлы сәнгатен алсак та, беренче караштa ул күбрәк дини-мифологик образларга, «изгеләргә»: Мәрьям ана белән Гайсәгә, фәрештәләргә, яки Гайсәнең шәкертләренә – апостолларга багышланган, хәтта тәре сурәтләү – икона сәнгате барлыкка килү дә шуны раслый.

Кешенең хыял көче белән тудырылган, үзе өчен үрнәк булып саналган ул образлар аша язучы, рәссам дөньяга карашын үткәргән, чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдергән һәм җәмгыятьнең башка член-

[1] Кулъязмада булмаган соңгы бүлектәге мисалларны без «Дастане Могҗизат»ның 1855 елгы Казан басмасы буенча алабыз һәм «Могҗизат» дип битләрен күрсәтәбез.

нарына яхшылык турындагы мораль кагыйдәләрен бирергә тырышкан. Бу язучы дини-мифологик образлар аша үз заманы кешеләрендә булырга тиешле, үзе күрергә теләгән сыйфатларны чагылдырырга омтылган. Ул образлар яхшылыкның идеалы саналган һәм укучы аларны шулай кабул иткән дә. Башкача булганда, борынгы грек, Урта гасырлар рим сәнгатьләренең һәм әдәбиятларының әһәмияте булмас та иде, ә алар әле дә безне рухландырып, таңга калдыралар. Гомерның, Рафаэльның, Урта гасыр рус рәссамы Рублевның даһилыклары да шунда ки, алар идеаль булып саналган дини, мифологик сюжетлар аркылы кешелек сыйфатларын, яхшылык морале принципларын үткәргәннәр. «Әдәби портретта чагылган бу яхшылык идеалы аерым шәхес зәвыклары белән түгел, социаль строй тарафыннан тудырыла» һәм «үзеңне яхшы тоту идеаллары әдәбиятка тормыштан килә» [Лихачев, с. 58, 60], – ди Лихачев.

Бер яктан, дини-мифологик сюжет яисә образ; икенче яктан, зур художество көченә ия булган әдәбият, сәнгать әсәре. Бу катлаулылыкны аңларга безгә марксизм-ленинизм өйрәтүләре ярдәм итә. К. Маркс борынгы мифологик сюжеттагы сәнгать һәм әдәбият әсәрләре хакында болай ди: «Моны аңлаудагы кыенлык шуннан гыйбарәт ки, алар һаман әле безгә әдәби зәвык бирүдә дәвам итәләр һәм билгеле мәгънәдә норма һәм иң югары үрнәк булу әһәмиятен саклыйлар» [Маркс, 1951, с. 205]. Сөләйман Саксини әсәрләре, «Дастане Могҗизат»ка шул яктан килгәндә, без андагы идея-эчтәлекнең каршылыклы булуын да, художество югарылыгын да һәм шагыйрьнең эстетик, фәлсәфи карашларының дәрәҗәсен дә аңларбыз.

Шагыйрь – үз заманы вәкиле, тарихи шәхес. Аның омтылышларының киңлеге дә, чикләнгәнлеге дә шул чор җәмгыятенең тормышы белән бәйле. Тарихта бөтен Урта гасырлар буена Көнбатышта – христианлык, Көнчыгышта ислам дине феодаль дәүләтләрнең югары санкциясе булып тордылар, шунлыктан, кешеләрнең хисләре дини азык белән туенып тәрбияләнгән була [Энгельс, 1952, с. 49]. Шушы хакыйкатьтән чыгып килгәндә, ислам дөньясындагы Урта гасырлар шагыйренең иҗатын дөрес аңлап булыр.

Барлык диннәр кебек, ислам дине дә чынбарлыкны фани, бетә торган нәрсә дип өйрәткән бер вакытта, Сөләйман Саксини дөньяны матур бер күренеш, ә кешене шул дөньяны бизәүче итеп күрә:

Дотың имди җан колагың бу сүзә,
Та бәйан идәм бу сүзи хуш сезә:
Хак Тәгалә чөн йаратты адәми, –
Кыйлды адәмилә мөзәййән галәми,[1]
Адәме лотф әсси хак вирде вөҗүд,[2]
Бойурды, фәрештәләр кыйлды сөҗүд.[3]
(9)

[1] Кеше белән галәмне (дөньяны) бизәде.
[2] Шәфкатьлелек иясе – Алла кешегә тереклек бирде.
[3] Сөҗүд – сәҗдә.

Дөньяны матур күрсәтер өчен барлыкка китерелгән кешенең иң беренче сыйфаты – яхшы холкы аның үзен күркәм ясый.

Һәр нә дөрле кем сәгадәт вар дорур,
Йахшы хой, күркле гадәт вар дорур.
(7)

Юлның мәгънәсе: дөньяда нинди генә күп төрле бәхет булмасын, матур гадәте кешенең иң яхшы табигате – характеры (хой) санала. Яхшылык, игелек идеясен шагыйрь башка әсәрләрендә дә үткәрә. Сөләйман алда телгә алынган «Зөһрәт әр-рийаз»да, «Тәнбиһ» дигән әсәрдән файдаланганлыгын әйтеп, юмартлык һәм саранлык турында бер өзек китерә.[1]

Шагыйрь анда үгет-нәсыйхәт морале укып, җәмгыятьне савыктырырга тели. Эш юмартлыкны саранлыкка каршы куюда гына түгел. Кеше юмарт һәм игелекле икән, ислам динендә булмаса да, ул – оҗмахлы. Язучы, хәтта тәмуг белән куркытып булса да, милек ияләрен рәхимле-юмарт итәргә тырыша. Бу – бөтен Урта гасырлар буена дәвам итеп килгән һәм киң таралган, күп халыклар әдәбиятларына уртак булган философия. XII йөз Идел буе төрки, болгар әдәбияты да гомумкешелек культурасы сорауларыннан читтә тормаган. Аның алдынгы язучылары шул чор җәмгыятендәге прогрессив идеяләрне күтәреп, аларны сүз сәнгате, образлар аша укучыларга җиткерергә тырышканнар. Күренгәнчә, бу дөньяви идеяләр дини сурәтләр белән төсмерләнеп, бергә үрелеп бирелгәннәр. Сөләйман Саксини башкаларда булырга тиешле юмартлык, гаделлек, игелекне шул идеаль образ аша бирә.

Мөхәммәднең авырган вакытында кызы, оныклары белән сөйләшү моменты да гади, дөньяви итеп сурәтләнә:

Мостафа диде: дотуңлар, дорайым,
Ул йаранларым катына варайым.
Күрәйем бер дәхи ул йаранлари[2],
Йәнә бән күрмисәрем анлари.
Һәм дәхи анлар бәни күрмәисәр,
Сөхбәтүмә[3] дөньяда ирмәисәр.
Һәм үлем айрусәрдүр безләри,
Дөрр йәшилә[4] дәхи дулды күзләри.
(25)

Диниләр тарафыннан пәйгамбәрлек таҗы кидерелгән Мөхәммәд бу юлларда гади кеше сыйфатларына ия булган конкрет, җанлы образ булып сурәтләнә. Алай гына да түгел, ул балаларыннан, дөньядан үлем мәңгелеккә аерачагы турында хәсрәт белән янып сөйли, аны шушы фаҗига борчый. Бу – әсәрдәге көчле кичерешле урыннарның

[1] «Зөһрәт әр-рийаз»дан өзек алган «Кагыйдәтес-Сөнусия» әсәре З. Максудова китапханәсендә саклана.

[2] Йаранлари – якыннары.

[3] Сөхбәтемә ирмәисәр – киңәшемә, мәҗлесемә ирешмәячәкләр.

[4] Дөрр йәшилә – энҗе яшьләре белән.

берсе. Мөхәммәдне дә, Гайсәне дә ул заман кешесе үзенә идеал итеп таныган һәм алардан үрнәк алырга тырышкан. Бу хакыйкать әсәрдә шулай сурәтләнгән дә.

Шагыйрь үзенең геройларын яратып, бирелеп сурәтли, әйтерсең, аның күңеле саф бер чишмә һәм аңардан өзлексез хисләр тасмасы сузыла. Шагыйрь яшәү яменә, җир тормышына гашыйк. Хәзерге төшенчә белән әйткәндә, шагыйрьнең дөньяга өмет белән карашы, чынбарлыкка мәхәббәте аның әсәренә баштан ахырына кадәр үзенә бер җылылык, күтәренке рух бирә. Күпчелек халыкка ягымлы карап, теләктәшлек күрсәтү, аларга ярдәм кулын сузып, игелекле, юмарт булырга өндәү – әсәрнең әһәмиятен тагын да күтәрә. Дини образлар аша эш итүгә карамастан, әсәрдә суфилык идеяләренең урын алмавы да игътибарга лаек.

Шик юк ки, Сөләйман Саксини – югары рухани катлаулар вәкиле: ул – феодаль дәүләтнең турыдан-туры яклаучысы булган ислам дине карашларын чагылдыручы, хакимлек итүче идеяләрне үткәрергә тырышучы. Ә «теләсә нинди вакытның хаким идеяләре һәрвакытта тик хакимлек итүче сыйныфның идеяләре булалар» [Маркс, Энгельс, 1952, с. 54].

Әмма Урта гасырларда яшәгән күп язучыларның дөньяга карашлары катлаулы һәм каршылыклы. Ул заман каләм остасын тик бер сыйныф вәкиле итеп, шул социаль катлауларның гына дөньяга карашын чагылдырган дип әйтеп булмаган кебек, әсәрнең идея-юнәлешен дә авторның тик шәхси карашларына гына кайтарып булмый. Чөнки, Маркс сүзләре белән әйткәндә, «кешенең асылы аерым индивидка гына караган (хас) нәрсә түгел. Үзенең чынлыгында ул (асыл) иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең җыентыгы» [Маркс, 1952, с. 55, приложение].

Теге яки бу язучының дөньяга карашының катлаулы булуының сәбәбе дә шунда. Ныклап өйрәнгәндә генә, шагыйрь Сөләйман Саксини иҗатында без теге яисә бу тенденцияләрнең ни дәрәҗәдә чагылышын күрә алырбыз.

Бер яктан, барлык нәрсәләргә кул селтәргә өндәп, теге дөнья өчен генә яшәргә чакырган ислам өйрәтүләре; икенче яктан, кешенең җирдә яшәве үзе бер гүзәллек булу. Менә шул җир тормышында шагыйрь Сөләйман ямь таба. Аныңча, кеше гомеренең чын мәгънәсе дә әнә шул чын тормышта яшәвендә һәм дөньяда игелекле, ярдәмчел булып, үзеңнән түбәннәр белән «ит-икмәк бүлешүдә».

Шагыйрь үзенең әнә шундый дөньяви теләкләр белән гомер кичергәнлеге турында сөйли.

«Дастане Могҗизат»ны язган вакытта, Сөләйман озын гомер юлы үткән, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, чәч-сакалы агарган, олы яшьтәге акыл иясе, карт бер хәким булгандыр дип уйларга туры килә.

Аһ ки бән нидәм, әмрени дотмадым,
Бер көн ул дидеки йула кәтмәдем.
Назәнин[1] гомри каму[2] вирдем йилә,

[1] Назәнин – матур, нәзәкатле.
[2] Каму – барысы.

Нәфсем арзуларына[1] йилә-йилә[2].
Гомремнең кадрен һәргиз[3] белмәдем,
Имди кем белдем, гомри булмадым.
Сач-сакал агарды, күңел кап-кара,
Кылмадым бер эш, ки карам агара.
(«Могҗизат», б. 43)

Күренә ки, шагыйрь дөньялыкта дин кушуы белән генә яшәмәгән: тормыш шартлары, әйләнә-тирә мохит аны үз эчендә мәшәкатьләнергә, үз юлыннан атларга мәҗбүр иткән.

Бер йарамаз фигълемез тәрк итмәдек[4],
Ахирәт бабында тәдбир итмәдек.[5]
Күңлемез милкен абад әйләмәдек.[6]
Үлүмемез чөн йараг әйләмәдек.
Хакка лайык һич йук әгъмалемез[7],
Белмәзез ки нулисәр әхуалемез.[8]
(«Могҗизат», б. 41)

Шулай итеп, үлгәч хәлебез ничек булыр икән дип, шагыйрь шикләнеп тә куя, чөнки ул теге дөнья өчен әзерләнеп яшәмәгән. Ә кеше гомере мәңгелек түгел, соңгы чиктә ул үлем белән киселә. Аныңча, фаҗига әҗәлдән котыла алмауда гына түгел, үлгәч, туфракка әверелеп юкка чыгуда.

Һәр нә дәклү чук йәшәрсә бер кеши,
Гакыйбәт үлмәк дорыр аның эши.
Һәр кем ула гакыйль, дәүләтлү әр[9],
Вагыйз, насих[10] аңа үлүм йитәр.
Белүрез чөнкем үлүрез гакыйбәт,
Черүбән туфрак улурыз гакыйбәт,
(«Могҗизат», б. 41)

дип, шагыйрь борчыла, уйлана, үткәннәрен башыннан кичерә.

Тормышта ул, үзе теләп-теләмәвенә карамастан, дөньяви уйлар белән яшәргә мәҗбүр булган. Сөләйманның тирән кичерешләр белән тулган юлларын дулкынланмыйча укып китү мөмкин түгел. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Сөләйман Саксини вагыйз – дини вәгазьче, нәсыйхәтче – насих кына түгел, киресенчә, ул дин таләпләрен үтәмичә, үзен уратып алган тормыш мәшәкатьләре белән мавыгып, дөньяви теләкләр белән гомерен үткәргәнлеге турында сөйли. Моны

---

[1] Арзу – теләк.
[2] Йилә-йилә –ашыгып, йөгереп.
[3] Һәргиз – бер дә, һичкайчан.
[4] Тәрк итмәдек – читкә какмадык.
[5] Тәдбир итмәдек – уйламадык, хәзерлек күрмәдек.
[6] Абад әйләмәдек – төзекләндермәдек.
[7] Әгъмаль – эшләр.
[8] Нулисәр әхуалемез – хәлебез ничек булыр.
[9] Әр – ир.
[10] Вагыйз, насих – вәгазьче, нәсыйхәтче.

ачыграк күреп, яхшырак төшенер өчен, дастанның ахырында шагыйрь үз хәле хакында сөйләгән бүлектән тагын бер өзек алыйк:

Бәндәм ул йөзе кара гасый[1] кол,
Бунчалайын[2] гасый кол кәлмеш дәгел.
Бер нәфәс[3] йукдыр ки гыйсйан[4] итмәдем,
Һәм дәхи бер дугры йула кәтмәдем.
Һәр нәфәсдә эшләдем бән чук гөнаһ,
Белең, гөнаһчен кыйлдым бән бер көн аһ...
Хакка лайык эшләмәдем бер гамәл[5],
Эшләрем җөмлә зәгалилә зәгаль[6].
Ахирәт әхаалени зикер итмәдем,
Нулисәр[7] хәлем дәйү фикер итмәдем.
Хәлемең, хуш, бәгъзесен кыйлдым бәйан[8],
Бундан артук йавыз эшем чук ниһан[9].
Кемсә белмәз, ничә хәлем вар дорыр,
Ул белүр, кем галимел-әсрар[10] дорыр.
Гизлү хәлем бер булисә әшкяр,
Дашлар илә әйләйәләр сәнгсар.[11]
(«Могҗизат», б. 43)

Шулай итеп, шагыйрь үзенең үткән гомер юлын ачып бирә. Аның дөньялыкта кылган гамәлләре ислам таләпләренә каршы булган һәм шул «[Аллага каршы] явыз эшләренең күбесе яшерен» булып кала. Ул тормышны зәвык белән үткәргән, теге дөнья өчен дә үзен әзерләмәгән, чәч-сакалы агаргач кына, дин кушканнарны үтәми яшәгәнлеге аның исенә төшә.

Димәк, эш әсәрдәге геройның ярым дини, яисә фантастик-мифологик сюжет белән бәйләнгән булуына түгел, бәлки аңа салынган һәм шуның аша үткәрелгән идея юнәлешендә. Сөләйман Саксини «Дастане Могҗизат» әсәрендә чынбарлыкны җәмгыять ирешкән сәнгатьчә фикерләү дәрәҗәсендә чагылдырган, үз чоры әдәбиятының алымнары һәм таләпләре нигезендә иҗат иткән.

### «Дастане Могҗизат»тагы сурәтләү чаралары

Шагыйрь чынбарлыкны гәүдәләндерүгә үзенең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып килә һәм аның иҗат лабораториясендә туган шигъри юлларында үзенчәлекле рәвештә үз заманы рухы чагыла.

[1] Гасый – гөнаһлы.
[2] Бунчалайын – мондый, бу кадәр.
[3] Нәфәс – сулыш алу кадәр кыска мизгел, вакыт.
[4] Гыйсйан – фетнә, гөнаһка бату, боерыкны тотмау.
[5] Гамәл – эш.
[6] Юлның мәгънәсе: эшләрем барысы да ялган, алдашулар белән тулы.
[7] Нулисәр – ничек булыр.
[8] Кыйлдым бәян – аңлаттым.
[9] Юлның мәгънәсе: моннан башка явыз эшләрем күбесе яшерен.
[10] Галимел-әсрар – серләрне белүче (Алла).
[11] Бәетнең мәгънәсе: Әгәр яшерен эшләрем билгеле була калса, мине ташлар белән кыйнаячаклар.

Моның укучыга ничек барып җитүе һәм тәэсир итүе авторның сүз белән оста эшли белүенә бәйләнгән.

Сөләйманның шагыйрьлек көче, иң беренче чиратта, аның сүзгә мөнәсәбәтендә сизелеп тора. Шигърият сүзенә ул менә ничек карый:

Бу күңлүм Мисрынә[1] кыйлдым сәфәр,
Багладым[2] анда нәчә тәклү шәкәр.
Ачалум ул шәкәрең тәңин уш,
Йимәдән[3] җануң сафалар булур хуш.
Илә ләззәтлү шәкәрдүр бу шәкәр:
Кем шәкәр бунуң катында бер хәҗәр[4].
Бу мәгани[5] шәкәрен гәр йиеп сән,
Дөнйада шәкәр бу имеш дийәсән.
(11)

Шагыйрь шигырьдәге сүзнең кеше күңеленә кереп, аның хисләрен уятып дулкынландырган, фикерләренә канат биреп уйланырга мәҗбүр иткән, аны сөендерә торган көче хакында сөйли. Шикәр татлы, шикәрдән дә татлырак нәрсәләр бар икән – ул поэзия; кешеләргә шигърият бирә торган рухи рәхәтлек, ләззәт янында гади шикәр хәтта бер таш кына ул, ди. Көчле чагыштыру бу.

Шикәр сүзе, поэтик образ буларак, бөтен Урта гасырлар болгар-татар әдәбияты аша үтеп, хәзер дә актив кулланылудан туктамый. Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»та бал-шикәр сүзен Йосыфның иреннәре белән чагыштыру өчен ала һәм:

Бал-шәкәрдән датлу(ы)рак дуадакларың,
Ике ләбең күңелеми үртәр имди, – ди.

Шикәр сүрәте М. Колый (Меллагол)да да нәкъ шушы мәгънәдә килә:

Кыз углан раушан ирер йакты көндин, –
Ата-анага ләззәтлектер шәкәр-балдин.

Ф. Бурнашта:

Телләрендә – бал-шикәрдән тәм генә...

Халык җырларында:

Шикәрләрдән тәмле, балдан татлы
Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең.
(«Мәдинәкәй» җыры)

Бу китерелгән берничә мисалда шикәр сүзенең татар поэзиясендә, борынгы вакытлардан алып, традицион сурәт булып, һаман да яшәп килгәнлеге күренә; халык авыз иҗатында ул тагын да күбрәк таралган.

[1] Мисыр – ил исеме.
[2] Багладым – күңел юнәлдердем.
[3] Йимәк – ашау.
[4] Хәҗәр – таш.
[5] Мәгани – мәгънәләр, фикерләр. Шигъри: соклангдыргыч.

Күгәрчен, былбыл, тавис, һома, сәмруг[1] кебек кош исемнәре Сөләйманда матур образлы сүзләр булып килгәннәр.

Дастанда, персонажның – Мөхәммәднең үлеп, арадан китүен шагыйрь һома кошы образы аша бирә.

Ул һома кош чеки пәруаз әйләди,
Җөмлә әсхаб фәрйад агаз әйләди.
(25)

*(Ул һома кош очып киткән чагында,*
*Җылый башлады бар дуслар тагын да.)*

Фантастик һома – бәхет кошы, тирән образлы сүз буларак, татар поэзиясендә һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә әле дә яши. Менә бер-ике мисал.

Г. Тукайның халык җырларында:

Очырдым һомай, ай, кошларын,
Табалмадым кунган төшләрен.
(II, б. 322)

Ә. Фәйзидә:

Күктә очкан кошның исеме –
Һомаюнмы, Сәмрәү кошымы?

Әлбәттә, кайбер поэтик фигуралар артык актив кулланылмаска да мөмкин. Һомай моңа мисал була ала. Ләкин гасырлардан гасырларга күчә килә, алар барыбер традицион образларга әвереләләр. Болгар-татар әдәбиятында тавис та нәкъ шундый традицион сурәтләрдән санала. Менә дастандагы 21нче хикәяттән бер мисал:

Гаклу тауис ачды кирү пәру-бал,
Таки җәүланилә күстәрә җәмал.
(21)

*(Акыл тависы җәеп каурый-канатын,*
*Боргаланып күрсәтә гүзәл затын.)*

Табигатьнең үз законнары гына тудыра алган тавис каурый-канатларына күз явын ала торган гүзәллегенә карап, кемнәр генә сокланмый икән! Акылларны таң калдырган менә шул тавис Сөләйман Саксинида бөтен матурлыгы белән гаҗәп күркәм образ булып алга баса. Әлбәттә, моннан сигез йөз еллар элек иҗат ителгән шигъри юллардагы сүзләрнең мәгънә, тойгы, хис, омтылыш төсмерләрен аңлау һәм ул сүз энҗеләренең серләрен ачып бирү җиңел түгел. Сөләйман сүзне оста куллана белә – нәкъ шунда аның зур шагыйрь икәнлеге күренә дә. Тавис канатларын җәеп горур әйләнгәндә үзенең матурлыгын бөтен тулысы белән күрсәткән кебек, кешенең акыл көче дә илһамланып иҗат эшендә кайнаганда искиткеч көчкә ия булган тыл-

[1] Һома, һомай – кешеләргә бәхет китерә торган фантастик кош. Ышанулар буенча, һомайның күләгәсе төшкән кеше зур бәхеткә ия була, имеш.

Сәмруг – фантастик кош.

сымлы шигъри юллар тудыра ала. Шулай итеп, шагыйрь төрле сурәтләр, образлар аша тирән фикерләргә, эмоциональ хисләргә ирешә.

Г. Кандалыйда тавис, гандәлиб (сандугач), тутый кебек традицион поэтик чаралар хәтта бер строфада бер-бер артлы киләләр. Мәсәлән:

Йөзләре шәмс-камәрди[1]
Мисле тауис рәфтәси[2],
Авазы хуш гандәлибди[3]
Тутый кеби гөфтеси[4].
(«Шигырьләр», б. 155).

Үзенчәлекле тавис образын хәзерге татар шагыйрьләре иҗатында да очратып була. Мәсәлән, Шәйхи Маннур

Бибкәй матур үскән икән,
Үсеп буйга җиткән икән,
Күгәрчендәй көлгән икән,
Тавис коштай йөргән икән.
(Сайланма әсәрләр, 1951, б. 346).

дип, кызның нәзакәтен, күңелләрне дулкынландырган һәм әйләнәтирәгә ямь биреп торган сылулыгының камиллеген бик отышлы сайлаган «тавис коштай йөргән икән» сүзләре аша әйтеп биргән. Бер сүз кызның нәфислеген дә, купшылыгын да бирә алган. Димәк, традицион төс алган сурәтләр үлмиләр, һәр чорның язучысы аларны үз карашларыннан чыгып файдалана, аларга яңа мәгънәләр, төсмерләр өсти.

Югарыда «Дастане Могҗизат»тан тавис турындагы китерелгән бәеттән соңгы юлларында да чын шигърият аһәңе яңгырый. Шигырь болай дәвам итә:

Фикер сахрасы эченә керде хуш,
Мәгънә гөлзарында җәүлан орды жуш[5],
Уорды пәру-бален[6] бер-беренә:
Таки нәкыш, фәһм, фикрәт күренә.
Чумды дил бәхренә[7] һәм гаувасуар,[8]
Булды анда нәчә дөрре-шаһуар[9],
Алды, гыйшык базарына килде, аны,
Аңа гыйшык мөштәри кәлсүн кани?[10]

Шагыйрь сүзләрнең күбесен күчерелмә мәгънәдә куллана һәм шул нигездә тирән җанландыруларга ирешә: фикер сахрасы, мәгънә

[1] Шәмс-камәрди – кояш һәм ай кебек.
[2] Юлның мәгънәсе: йөреше тависныкы төсле.
[3] Гандәлибди – сандугачныкыдай.
[4] Гөфтеси – сүзләре, сөйләве.
[5] Юлның мәгънәсе: Мәгънә гөлбакчасында сәер итеп дулкынланды.
[6] Пәр вә бал – каурый-канат.
[7] Дил бәхре – күңел диңгезе.
[8] Гаувасуар – чумучы кебек.
[9] Шаһуар – иң кыйммәтле, ара бөртекле энҗе.
[10] Кани – кайда.

гөлзары (чәчәклеге); дил бәхре (күңел диңгезе), гыйшык базары һ. б. Гавасвар (чумучы – водолаз) диңгез төпләренә чумып, эре энҗе бөртекләрен зур тырышлык белән генә тапкан шикелле, шагыйрь дә тик күңел диңгезендә, фикер сахраларында, мәгънә гөлбакчаларында иҗат дулкыннарын кичкәндә генә сүз энҗеләреннән шигъри тасмалар барлыкка китерә алырга мөмкин, ди. Сөләйманның поэтик иҗат эшенә карашы шушылай. «Дастане Могҗизат» – баштан ахырына кадәр шундый образлы сүзләр белән бизәлгән поэтик әсәр. Анда: ширин сүз, энҗе дешләр (тешләр), катыг сүз, сәгадәт (бәхет) таҗын ору (кию), үлем зәхмәте, гафләт уйкусы (гамьсезлек йокысы), бәхре гыйлем (белем диңгезе), гүзәл йөзле, һома кошы, васлат (кавышу) җилләре, җан колагы, җан һомасы, күңел дәрьясы, сәрүе буйлуг, дөньядин сәфәр әйләде, сабыр пәрдәсе, канлы яшь, рәхмәт йагмуры (яңгыры), күңел күзе, йалан айак, йөзе ак, йөз суы, көн йөзе, йөзе кара, башы ачык кебек күчерелмә мәгънәдә килгән поэтик чаралар – троплар еш очрый.

Сөләйман бине Дауд кулланган образлы сүзләр, сурәтләр арасында бик борынгы формалары, хәтта заманыбыз телендә онытыла башлаганнары да бар. Мөхәммәд авырып яткан вакытында оныкларын соңгы кабат күрергә теләп, аларны янына чакырта һәм үкенечле сүзләр сөйли.

Бөйлә диде, йәшилә дулды күзи,
Диде: каны шул ике көрпә[1] кузый?[2]
Керделәр иүәрү чен аглашдылар,
Бабасының буйнуна чырышдылар.
Диди: җаным кузыйлар, нитмәк кәрәк,
Дәдәңез дунбагъ[3] тәрк итсә кәрәк,
(25)

Биредә Мөхәммәд оныкларына көрпә[4] кузый, җаным кузыйлар, ягъни бөдрә бәрәннәрем, җаным бәрәннәрем дип эндәшә. Йомшак, мамык йонлы мәгънәсендәге керпә сүзеннән оста файдалануның үрнәге Дәрдемәндтә дә бар:

Мачы, мачы пәскәеп,
Көрпә мамык төскәме...

Яисә:

Күтәр чәчкәйләрең, күтәр кабагың,
Күренсен йөзләрең, көрпә яңагың.
(Шигырьләр, б. 85)

[1] Көрпә – йомшак, бөдрә, мамык йон. Мамык, йон белән сырылган түшәккә, җәймәгә, юрганга да керпә диләр.

[2] Кузый – бәрән; дөнья; төнбагы.

[3] Дунбагъ – урын, ястык. Юлның мәгънәсе: бабагыз урынын ташлап китә булса кирәк.

[4] Көрпә – борынгы төрки телдә мәче мәгънәсендә дә кулланылган.

Җанвар, җәнлек балалары яисә кошлар исеме белән сабыйларга эндәшү, иркәләп, сөеп әйтү, мөрәҗәгать итү күп халыкларда һәм болгар-төркиләрдә да киң таралган. Мәсәлән, тоткынлыкта яшәгән каһарман Муса Җәлил югалган ирегең очып киткән кош белән чагыштыра:

Алтын иркем, азат тормышым,
Кая очтың киек кош булып?
(«Ирек»)

ди шагыйрь.

Мондый мисалларны татар әдәбиятыннан, халык дастаннарыннан, эпослардан күп китерергә мөмкин. Мәсәлән, колын сүзен образ итеп куллануга бер-ике үрнәк алыйк.

Дәрдемәндтә:

Колынкаем,
Кил җанкаем,
Йоклаек икәү.
(«Бәллү»)

«Бүз егет» дастанында, улының (Бүз егетнең) үтерелгәнен белгәч, ана күз яшьләрен түгеп, хәсрәтләрен белдереп, болай ди:

Күз алдымда бар булсаң,
Күрмәс мидем, колыным[1];
Үлгән йирдә бар булсам,
Үлмәс мидем, колыным.
(«Бүз егет», 1916, 60)

Хайваннар исеме белән бу рәвешле балага эндәшүне «Алпамыш», «Манас», «Раушан» кебек дастаннарда, шулай ук «Кузы-Күрпеч»нең казакъ, башкорт һәм татар вариантларында да очратабыз. Язма әсәрләрдә сурәтләү чарасы буларак кузы (бәрән) беренче XI йөз ядкәре Йосыф хас-Хаҗибның «Кутадгу билиг»ендә күренә.

Никү тир[2], ишеткел утачы[3] сүзи, –
Монуң мәгънәси укъ[4] – терелгел, кузый.
[Валитова, с. 99].

Яисә:

Йатыг әрмәс әрсә бу дәүләт үзи,
Нә әдгүнәң әрди бу кот, әй кузый!
[Малов, с. 268]

*(Бу дөньяда, байлыклары асылда шул кадәр түбән-әшәке булмаса,*
*Бу бәхет дигәнең нинди булыр иде, и кузый!)*

[1] Колыным сүзе белән баланы иркәләү XVII йөз әдәбиятыннан «Әбү Шәхмә» хикәятендә дә кулланылган.

[2] Никү тир – изге кеше.

[3] Утачы – табиб.

[4] Укъ – аңла.

Монда «кузый» поэтик фигура булып килгән. Ләкин «Керпә кузый» формасын без алда Сөләйманнан китерелгән мисалда күрдек. Шушы образлы сүз соңыннан халык дастаннарында геройның исеменә әверелә – аның асылында шул ук сөеп әйтү һаман да саклана. Казакъта ул: Кузы-керпеш, башкортта Кузы-керпәс, татарда Кузы-керпәч. Әмма Сөләйманда әле «керпә кузый» иркәләп әйтүне генә аңлата.

А. Вәлитова: хайван балалары исеме белән эндәшү элек малчылык белән шөгыльләнгән халыклар фольклорына гадәти күренеш дип яза [Валитова, с. 100]. «Кузы-керпәч һәм Баян-Сылу» эпосының казакъларда, башкортларда, шулай ук Көнбатыш Себердә һәм Урал якларында башкортлар белән бәйләнештә яшәгән татарлар арасында таралган булуы да шуның белән аңлатылса кирәк. Димәк, эпос элекке күчмә яисә ярым күчмә халыкларның тормышына җайлаштырылган. Болгар-татарларның төп халкы яшәгән Идел буенда бу эпосның язмышы башкарак юнәлештә киткән. Болгарлар – бик борынгы вакытлардан бирле нигездә утраклык белән яшәгән халык. Элекке вакытлардан ук шәһәр тормышы белән бәйләнгән үзбәкләрдә, госманлы[1] һәм болгар-татарларда бу эпосның башлангыч легендасы нигезендә икенче игезәк төре барлыкка килгән булса кирәк. Бу – Таһир белән Зөһрә турындагы эпос яки дастан. Бу исә утраклыкта яшәгән һәм шәһәрләре булган халыкларның тормышы белән бәйләнгән. Безнеңчә, ике төр эпосның да генезисы бар. Ләкин аерым халыклар аны үзләренең тормыш барышына яраклаштырып эшкәрткәннәр, тарихи социаль яшәү шартларына җайлаштырганнар.

Биредә Сөләйман Саксинының «Дастане Могҗизат»ындагы сурәтләү чараларына карата кайбер мисаллар гына алынды. Ул образларның күбесе бүген дә әле татар поэзиясендә көчле яңгырыйлар, аларның эзләрен халык авыз иҗатында да күреп була.

Сөләйманда:

Гәр аңа күңел күзе илә бака сән,
Җан колагына бу дөрри дака сән.
(19)

*(Аңар күңел күзе салсаң –*
*Җан колагына бу энҗене тагарсың).*

Күңел күзе сурәте шулкадәр таралган ки, һәр болгар-татар шагыйренә таныш, хәтта ул: «күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – күрә алмас» дигән мәкальгә дә төп элемент булып кергән. Шагыйрьнең күләгә сүзен куллануы да үзенчәлекле.

Нур иде башдан айага гәүдәси,
Бу гайандыр[2], нурың улмаз күл(ә)гәси;
Күләгә золматдан төшә һәр йирә,
Күләгәне нурдин бу күз канда күрә.
(19)

---

[1] Әхмәд Уразай «Таһир – Зөһрә»сен госманлылардан алам дигән.

[2] Гайандыр – ачык.

Сөләйманча, күләгә – караңгылык, золмәт, кайгы, наданлык билгесе. Татар поэзиясендә һәм әдәбиятында күләгә, образ буларак, күп очракта хәзер дә тискәре мәгънәдә кулланыла. Муса Җәлил «Моабит дәфтәре»ндә кайгыны «кара күләгә», үлем куркынычын «үлем күләгәсе» дип бирә.

Айлар буе минем бүлмәмдә,
Булып ямьсез кара күләгә,
Боектырып назлы күңелне,
Карауладың минем гомерне.
(«Шатлыкны каршылап»)

Яки:

Һәр тыкрыкта үлем күләгәсе,
Һәр ишектә коллык йозагы...
(«Серле йомгак»)

Халык әдәбиятында аерым сурәтләр, образлы сүзләр, шул чаклы нык, тотрыклы булып әвереләләр ки, гасырлар, хәтта мең елга якын вакыт үтүгә дә карамастан, алар шул әдәбиятта әле дә солдат булып калалар. Димәк, аерым образларның озын гомерле булуы шул әдәбиятның үзенчәлеге, эчке үсү закончалыклары белән бәйле.

**«Дастане Могҗизат»ның теленә карата**

Болгар заманындагы Идел буе төрки теле Галинең «Йосыф китабы» һәм кабер таш язулары буенча гына билгеләнә килде. Ләкин шул өлкәдә язылганы анык билгеле булган әсәрләр әле юк иде. Ниһаять, «Кыйссаи Йосыф»ның әүвәлге хәбәрчесе булган Сөләйман Саксини әсәрләренең культурабыз тарихында яңадан тергезелүе шул чорлар әдәбияты һәм тел ядкярләрен янәшә куеп өйрәнү өчен киң юл ача.

«Дастане Могҗизат»ның теле – борынгы; Идел, Урал буе төркисе. Ул заман төрки телләрдәге уртаклык хәзергегә караганда да күбрәк булган. Шуның өчен дә Сөләйман Саксини дастаны теленең угыз, харәзм төркисенә якын булуы гаҗәп нәрсә түгел. Шундый уртаклык булуга карамастан, аның төп лексик составы Идел буе төркисен тәшкил итә, шуңа күрә ул хәзерге татар теле белән нык бәйләнгән. Кайбер сүзләрне алып карыйк.

**Исемнәр:** ат, ата, ана, атасы, айагына, агач, аккош, асман һәм күк, бодак, даш (таш), туфрак һәм тупрак, җәннәт һәм оҗмах, дәрт һәм дәрд, күз, киңәш, көн (кояш), кап (капчык дигәндәге), катына (янына), кот (бәхет), йөз, йолдыз һәм кәүкәб, йир йөзе, йапрак, йөз суы, өү, ү (мишәр сөйләшендәге «ү» кебек).

**Сыйфатлар:** айрук (аерым), ак (агыйде – ак иде), бойурмадуг эш (боермаган эш), каты һәм катыг, канку (кайсы), канкусы (кайсысы), ушбу, дөрлү (төрле), күрклү, чук сәлам, котлу (бәхетле), күзлү, сүзлү, гүзәл, олы (олы кол), йалан айак, айрулдуг сәгатдә, булдуг йул.

Дастанда **сан** исемнәреннән хәзерге вакытта кулланылганнарыннан барысы да бар, ләкин: бең язылa һәм икенч, өченч формасы да очрый.

**Алмашлыклар:** бән, сән, ул һәм у; без, безләр, анлар һәм улар; бу, буны, булар, бунлар (бонлар) һәм моны, моның, монлар.

**Фигыльләр һәм хәл фигыль формалары:** алмак, элмәгә, белүлде (белдерде), булды һәм улды, йагар (кар йагар), кыйлур, котлады, дугды (туды), улмаз, күстәр, күргүзде, ачалум, сачалум, озар (озынаер), уарса, килсә, йагыйсәр (яуачак), дугыйсәр (туачак), илт, нәтде – нишләде, әйтде; аглайу (елап), йиңмәйүп (җиңмичә), тугдурмасачы, кыйлубән, кәлүбән, сөйләгел.

**Рәвешләр:** уйагыйкән, бончалайын, бераз, мончә, бөйлә-бүйлә, гомреңезчә, тулунчә, айрунчә, ирак (йырак), ари (ару, таза), кирү (кире кәлде), үтә бакды, каршу һ.б.

**Ярдәмлекләрдән:** бәлки, чөнкә-чөнки, һәм, дәхи, ирди, имди, иде һәм изе (Минзәлә ягы сөйләшендәге кыдыл бодай дигәндәге кебек); үзе, үзрә һәм өстенә, илә (күп очракта дастанда кушылып языла: аныңилә (аның белән), ичрә һәм ичендә, гәр, әгәр, гәрчә, йәнә, ки.

Бу китерелгән сүзләр белән беррәттән, «Дастане Могҗизат»та бик борынгы сүзләр һәм иске формалар бар. Монда аларның кайберләрен генә китерәбез. Мәсәлән, агаз – башлау; фәрйад агаз әйләде (җылый башлады).

Агды – күтәрелде: йәнә күккә агды (күтәрелде). «Йосыф китабы»нда (40): хәрир (ефәк) киде, орынды, тәхтә агды (тәхеткә күтәрелде).

Андук: әүвәл анук аны, кем әүвәлдүр ул.

Андук искә алды, «аң», «аңламак» сүзеннән: зиһенгә китерү, хәтерләү, искә алу, аңлау, белү мәгънәсендә. Мәсәлән, Ф. Әмирханда: Рәсемдәге матур күзләренең матур елмаешлары хөр вә ялгыз үскән тубылгы чыбыгын андыра... (т. 1, 484). Бу сүз «Кыйссаи Йосыф»та да шул мәгънәдә килә: Аны сезгә андырмага үгъдә кыйлдым (40).

Уграды – очрады:

Бу фирак уды кәмә кем уграды,
Униградугың йөрәкен дуграды.

Мәгънә:

*Бу аерылышу уты кемгә очрады,*
*Шул очраучының йөрәген труклады.*

Уграды – очрады, угурмак, угратмак – туры килү, якынаю, очрашу. «Кыйссаи Йосыф»та да бу сүз нәкъ шул төшенчәдә алына.

Йосыфә бакмага ууградылар, –
Кәнд әлләрен кәсүббән дуградылар.
(56)

Мәгънә:

*Күрергә дип Йосыф белән очраштылар,*
*Шулчак үз кулларын кисеп турадылар.*

Әбелмәних Каргалыйда: «Бер бәлайә уграмышым нагәһан», ягъни кинәт бер бәлага очрадым. Сөләйманда сил – сөрт сүзенең кулланылуы да тел факторы буларак кызык һәм әһәмиятле:

Бәс рәсүл кәм диде: йилең, и кызым,
Сил йәшеңи, аглама, тотгыл сүзем.
(25)

Икенче урында:

Рәсүл икенде намазын кыйлмышиде,
Дога кыйлып, әл йөзә силмешиде.
(20)

Җөмләләрдән күренгәнчә: сил йәшеңи – яшеңне сөрт, әл йөзә силмешиде – кулын йөзенә сөртте, сыйпады була. Шушы сил-сел яисә силмә, силмәк, селмәк тамырыннан ясалып, татар телендә хәзер дә иң актив булган «сөлге» сүзе яши.

Касыйм татарлары телендә «сөлге» сүзе башкачарак әйтелештә: «селе», «сәлә» (Диалекталь сүзлек, III, 137 б.) [Махмутова, 1955, с. 155], чөнки аларда «г, к» авазлары әйтелми: күлмәк урынына «үлмәэ» диләр. Бу, ягъни «селе» – «сәлә», «сил» тамырыннан ясалып, хәзерге көнгә кадәр сакланган тагын бер күренеш.

«Дастане Могҗизат»та актив кулланышта булган – исар-исәр кушымчалары да борынгы үзенчәлекле фигыль формаларыннан. Безнеңчә, бу – барлык төрки телләргә дә хас күренеш түгел. Ә. Нәҗип Харәзминең «Мәхәббәт-намә»сендә очраган бу форманы чыгышы ягыннан угызныкы итеп карый һәм Урта Азия язма истәлекләрендә аның күренмәгәнлеген әйтә. Без аны Идел буе болгар-кыпчак (татар), Харәзем төрекләре, азәрбайҗан, госманлы Урта гасырлар язма ядкярләрендә очратабыз. Әмма Идел буе төрки (болгар-татар) әдәбиятында ул XX йөзнең башларына кадәр кулланудa була.

«Дастане Могҗизат» бу формада килгән фигыльләргә бик бай.

Кортарисәр (коткарыр), әйләисәр (шулай эшләр), улисарз (булырбыз), куйисәр (куячак), уирисәрем (бирермен), диисәр (дияр), айрусар (аерачак), күстәрисәр (күрсәтер), охшаисар (яратыр).

«Дастане Могҗизат»тагы сүзләрнең яисә фигыль формаларының кайсын гына алсак та, без аларның болгар-татар әдәбияты истәлекләре теле белән, хәтта халыкның хәзерге җанлы сөйләме белән органик бәйләнгәнлекләрен күрербез. Менә бер мисал:

Хури җинан[1] шад улдугый
Дугдугый ау кәлди йәнә.
(3)

Биредә «шад улдугый» һәм «дугдугый ай» – «шат булган», «туган ай» була, ягъни үткән заман сыйфат фигыле хикәя фигыльнең үткән заманына – кы-гы, ке-ге аффикслары кушылу белән ясалган. Бойурмадуг эш һич итмәде – боермаган эшне һич эшләмәде дигән сүз. Сөләйман бине Дауднын дастаны бу форманы теркәгән бердәнбер әсәр түгел, соңгы вакытка кадәр татар язучыларының әсәрләрендә ул урын ала.

[1] Хури җинан – оҗмах хурлары (кызлары).

Әбелмәних Каргалыйда:

Туры кәлеп аңа йул күстәрделәр,
Алдукый флюресен һәм вирделәр.
(«Тәрҗемәи..., 25)

Алдукый флюресен – алган акчасын.

Г. Ибраһимовта: «Зәки ачлык, бу кадәрле кыенлык күрдеги кеби, әүвәлге көндән үк... вәхшәтләрне күрә башлады. Зәкинең хәлфәсенең шәкертләре бик күп булдыгыннан, тиз дәрес алырга чират җитми иде («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»).

Татар әдәбияты классикларының әсәрләрендә һәм халыкның җанлы сөйләшендә әле дә кулланылган шушы булдык – булдыкы – булдыкыннан формасын Р. Шәмгунованың борынгы күренеш итеп каравына тел галиме Э.Р. Тенишев каршы чыгып, -дык, -дек (калдык – җыентык) формасы татар теленең үзенә хас түгел, ул форманың Г. Ибраһимов тарафыннан кулланылуы «тышкы күренеш ягы, төрекләргә охшарга тырышу модасына өстенлек бирү генә», – дип яза [Тенишев, 1966, с. 216–220].

Гаҗәп парадокс бу!

Э.Р. Тенишев фикеренчә, Г. Ибраһимовта мода артыннан куу булсын ди. Ә Г. Тукай публицистик мәкаләләрендә ул тышкы ясалмалыкны күз алдында тотмагандыр дип уйларга кирәк. Менә шул формага Тукайдан мисаллар: «шуның өчен аларга, һәр милләттә **булдыгы** кеби... җәмгыяте хәйрия ясау лөзүме (кирәклеге) күптән хас ителмәктә иде (т. III, 132 «Җәмгыяте хәйрия»). «Баз мәхфи улмая ки (аннары яшерен булмасын), без сезләрни Думага сайлап мәшәкатьләнеп әбәрдек хөкүмәт сайларга **кушканлыгы** өчен, юкса безгә кирәк нәрсә **булдыгыннан** түгел (т. III, 59. «Казаннан Думага телеграм»).

Мисаллар китерелгән чыганаклар икесе дә – Тукайның памфлетсатирик мәкаләләре. Мода артыннан куу дигән нәрсә мөмкин түгел.

Татар теле диалектларындагы җанлы сөйләмдә: «бар булдыгы – шул инде», «баргым кели» [Махмутова, 162, с. 143] диюләр дә шул формага керә. Булдыг формасы борынгы уйгур, госманлы телләрендә һәм угыз теленең яргу диалектында да булган [Рясянен, 1955, с. 169–170].

Бардыг формасының «Дастане Могҗизат»ка, «Кыйссаи Йосыф»ка, Гариб Болгариның «Былбыл вә Гөл»енә барып тоташуы һәм аннан соңгы әсәрләрдә, җанлы сөйләм телендә һаман да яшәп килүе шушы телнең үзенә хас булган үзенчәлек икәнлеген раслый.

«Дастане Могҗизат»та аерым сүзләрне, беренче карашта тиеш күренмәгән урында, әлиф аша язу очраклары бар. Мәсәлән, без күрергә күнеккән *тибрәнде* сүзе *тибрәндәи* формасында язылган:

Варды ул тагга, орды кадәм,
Таг тибрәнди кадәм ордуг дәм.
(19)

Мәгънә:

*Тауга барып ул аяк басты,*
*Аяк баскан чагында тау тибрәнде.*

Гарәп хәрефләре белән язылган тибрәндәи сүзен ачыграк аңларга тырышсак, тибрәндейе, ягъни тибрәнде-эйе дип бирергә мөмкин һәм моның шулай булырга тиешлеген шигырь юлындагы үлчәү дә тели. Әгәр без татарның урыннардагы җанлы тел фактларына күз салсак, моның шул телнең үзенчәлекле сөйләшен чагылдырган күренеш икәнлеген аңларбыз. Мәсәлән, диалектология материалларына караганда, Чистай яклары, Куйбышев өлкәсе татарларына бардымие (бардым-эйе), килдемие (килдем-эйе) дип сөйләү характерлы [Шамгунова, б. 166]. Авторларның күзәтүенчә, болай сөйләү Тархан, Буа, Апас, Тәтеш тирәләрендәге татарлар телендә дә бик актив. Борынгы әсәрләрдәге бардуи, кабер ташларындагы бултуи (булдыи), тындуи (тындыи) формасы үзенең язылышы белән диалектлардагы нәнә шул бардыйе сөйләшенә бик якын. Бу күренеш – язуда болгар-татар сөйләшендәге үзенчәлекле әйтелешне чагылдырырга тырышу билгесе генәдер. Гариб Болгариның «Былбыл вә Гөл» әсәрендәге[1]:

Хали калдуи җаныдин бостан, баг...
Кәтдүкендин улдуи зар-зар, –

дигән юлларда калдуи – улдуи дип язылуның да сәбәбе шулдыр.

«Дастане Могҗизат»тагы шикелле «әлиф» белән язу үрнәкләре «Йосыф китабы», каберташ язуларында да бар.

Көн, җите сүзләренең кабер ташларында ку(а)н, җи(а)те рәвешендә әлиф белән язылуларын да шулай аңларга кирәк. Бу язылыштагы әлиф – «а» яисә «ә» авазын да тулы мәгънәдә аңлатмый. Бу күренешне шулай төшенергә безгә борынгы вакытларда «уау»дан соң «әлиф»нең график-язу билгесе булып йөргәнлеге дә ярдәм итә.

«Дастане Могҗизат»та характерлы мисал бар:

Аныңчен улды бу варлук камуа;
Ай, йулдуз, йир, күк, уҗмак, тамуа.
(6)

Биредә каму (барысы), таму (тәмуг) сүзләре ахырында язылган «әлиф»не тик график билге итеп карарга туры килә, чөнки аның бу урыннарда нинди дә булса аваз мәгънәсенә ия булмаганлыгы ачык. Аерым сүзләрне «әлиф» белән язу Болгарга килгән гарәп сәйяхларыннан Ибне Фадлан көндәлекләрендә дә урын ала. Мәсәлән, Башту(а), Вису(а), Йабгу(а), Ардакуа.

Зирәк акыллы сәяхәтче үзе булган илләрдәге Харәзем һәм бигрәк тә якыннан танышкан болгар төркиләрендәге сүзләрнең язылышындагы аерым нечкәлекләрне дә сизгән һәм аларны язуда сакларга тырышкан.

---

[1] [Кырыенда З. Максудова искәрмәсе: «Гариб Болгари хакында әле матбугатта сүз ачылмаган, шунлыктан аның иҗадыннан мисаллар китерү урынсызрак буладыр. *З.М.*»].

Болгар илендәге язу практикасында «уау»дан соң гына түгел, хәтта урыны белән «уау» белән бәйләнмәгән әлифне дә язу билгесе итеп карарга туры килә. XIII йөз галиме, «Тәрҗемани фарси-төрки вә могули» сүзлегенең авторы «уау»дан соң «әлиф» белән язу кайбер төрки халыкларда гадәт булып санала дип яза. Болгар-татарларда шушылай язу традициясе тагын да көчлерәк булган. Димәк, болгар-татар кабер ташларындагы әлиф белән язылган «көн», «җите» сүзләрен «кү(а)н», «җи(а)те» дип укырга урын калмый. Бу типтагы кабер ташларында күчте фигылен искә алмаганда, нигездә бултуи (булды) һәм тындуи (тынды) кебек ике генә фигыльнең язылган булуы: «булды»ның һәрвакыт «вафат» сүзе белән, «танды»ның сәфәр сүзе белән генә килүләре дә штамп формасына әверелгән язу традициясен генә күрсәтә.

Биредә «Дастане Могҗизат» телендәге сүзләрнең үзенчәлекле формаларыннан кайберләре генә күзәтү рәвешендә алынды. Төрлелек һәм үзенчәлекләр язу кагыйдәләре белән дә бәйләнгән булырга мөмкин. Ләкин әсәрнең язу-хатында төпле кагыйдә юк, бер үк сүзләрнең төрлечә язылышы очрый. Күп вакытта «с» астына, борынгы традиция буенча, өч нокта куелган. Иде, иле кебек ярдәмче фигыльләр күбесенчә үзеннән алда килгән сүз белән кушылып язылалар: аның илә – аныңилә, уң иде – уңиде, кыйлмыш иде – кыйлмышиде, кыйлмышди.

Сөләйман Саксини әсәрендәге сүзләрдән бик борынгы дип хисапланганнарын да без соңны вакытлардагы татар теле фактларында күрә алабыз.

Һәм һидайәт былбылы анда үти,
Һәм сәгадәт сөмбеле җанда бети.
(10)

Бу ике юлның ахырында килгән «былбылы үти» һәм «сөмбеле бети» дигәндәге «үти» (яисә «үтте»), «бети» (яисә «бетте») сүзләре «үтте, үтеп китте», «бетте – юкка чыкты» мәгънәләрендә килмәгән. Үти – сахра; үтмәк – сайрау һәм бети – үсә, бетмәк – үсү фигыленнән. Ул ике юлны хәзерге сүзләр белән:

*Һәм хак юл былбылы анда сайрый,*
*Һәм бәхет сөмбеле җанда үсә,* –

дип бирергә мөмкин.

Сөләйман Саксини дастанындагы әнә шундый борынгы саналган сүзләр дә татар әдәбиятының соңгы вакытларга кадәр саклап булган истәлекләрендә, хәтта халык җырларында да яшәп киләләр.

Канәфәр чәчдем – гөл бетте,
Гөл чәчәкләрен җил түкте.
(«Җырлар китабы», 1880, б. 7)

Аллар бетеп, гөлләр үскән
Безнең җанкәй битенә.
(«Җырлар көлтәсе», 1918)

Бу ике мисалдагы «гөл бетте», «аллар бетеп» тезмәләре дә «гөлләр үсте», «аллар үсеп» дигән сүз була. Халыкның зирәк аңы «Аллар үсеп, гөлләр үсеп» димәгән, үскән сүзен кабатларга теләмәгән, аның икенче синонимын кулланган. Яисә:

Бакчада гөлләр бетәдер,
Арасында былбыл үтәдер.
(«Җырлар», 1880, 20)

«Үтәдер» ягъни «сайрыйдыр – сайрый». Болар борынгы җырлардан булырга тиешләр, әмма алар – халыкның үзенең иҗаты, үз теленең үрнәкләре. Һәм болар барысы да татар теленең нигезендә Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат» әсәре теле ятканлыгын күрсәтәләр.

Югарыда китерелгән фактлардан күренә ки, Сөләйман Саксининың «Дастане Могҗизат» әсәре тел үзенчәлекләре һәм сурәтләү чаралары ягыннан болгар-татар әдәбиятының бөтен чорлардагы ядкярләре белән, хәтта каберташ язулары һәм халыкның җанлы сөйләм теле белән дә нык бәйләнгән. Димәк, ул – Болгар иле әдәбияты җимеше, болгар-татар поэзиясе мирасы.

## «Дастане Могҗизат»ның шигырь төзелешенә карата

«Дастане Могҗизат» – эшләнеше ягыннан чын мәгънәдә зур поэтик әсәр, Идел буенда хәзергә билгеле булган, иң борынгы хисапланган әдәби мирас. Аның шигъри юллары ниндидер бер трафарет калыпка салынмаган. Бу үзе генә шул заманда Идел буендагы төрки поэзиясенең колачы киңлеге хакында сөйли. Әсәрнең күп өлеше унбер иҗекле бәхре рәмәл үлчәвендә язылган, соңгы сүзләре рифмалашып килгән ике юллы бәеттән тора.

Су дик акызуп күзүңездән канлу йәш,
Агласунлар сездәр илә таг-у-таш.

Ләкин кайбер хикәятләр башка үлчәүдә һәм тәртиптә язылганнар.

Сусадым, суны теләдем эчмәгә,
Үирделәр бер кадәх[1] дулу ширбәти;
Кардан агыйди һәм суыгыйди,
Дәхи ширинди[2] шәкәрдән ләззәти...

Шигъри юллар шулай төзелеп китә, бәетләрнең икенче юлларындагы сүзләр генә рифмалашып килә. Алардагы аһәң һәм моң гармониясе ул юлларны бербөтен ясый.

Яисә строфаларның өч юлындагы соңгы сүзләр аваздаш килә, ә дүртенче юл калган куплетларда кабатлана яисә рифмалаша – яраша. Мәсәлән:

[1] Кадәх – кясә, савыт.
[2] Ширинди – ширин (баллы) иде.

Андан уман шәфагати,
Җанилә дотар сөннәти,[1]
Кәлең, идәлем хөрмәти, –
Дугдугый ай кәлди йәнә.
(3)

Шагыйрь Габделҗәббар Кандалыйның күп назымнары – көйле шигырьләре «Дастане Могҗизат»тан китерелгән әнә шул шигъри үлчәү һәм алымда язылганнар. Менә аның үзенең сөйгән кызын мактап язган кайбер юллары:

Йөзеңи[2] әйләде гөл тик,
Сачыңи кыйлды сөмбел тик,
Авазың итте былбыл тик,
Идүп фазлы гыйнайәти[3].
Гаҗәбдер бер билең анчә,
Ләбең ләгыль, дешең гончә[4],
Йук ирди күрдекем бончә,
Күрүбән күп кямаләти[5].
(«Сахибҗамал бәете»ннән, 25).

Кандалыйның бу юллары турыдан-туры Сөләйман Саксинының шигырьләрен хәтерләтәдер. Ул «Дастане Могҗизат» белән таныш булу гына түгел, аннан нык өйрәнгән, элгәрләренең мирасыннан иҗади оста файдаланган.

Сөләйман Саксини әсәрләре шигъри яктан нәфис эшләнгәнлеге белән аерылып торалар. Моның шулай икәнлеген югарыда китерелгән ике юллы бәеттән дә яхшы сизеп була:

Һәм һидайәт былбылы анда үтти,
Һәм сәгадәт сөмбеле җанда бетти.

*Һәм хак юл былбылы анда сайрый,*
*Һәм бәхет сөмбеле җанда үсә.*

Бу юлларда чын мәгънәсе белән төгәл рифмалар булу өстенә, тезмәләрдәге калган сүзләр – барысы да үзара бөтен яктан ярашып килгәннәр: сузык һәм тартык авазларның чиратлашулары да, алардагы яңгыраш та шигырьнең censorship бербөтен эчке музыкаль мелодиясенә барып кушылалар.

М. Кашгари үзенең сүзлегендә күп төрки халыкларның авыз иҗаты һәм язма поэзиясеннән шигъри үрнәкләр теркәгән. Анда нәкъ Сөләймандагы шикелле алым белән, бер үк үлчәүдә һәм формада язылган куплет та китерелә. Ул – болгар поэзиясенең беренче карлыгачларыннан, шигърият бакчасының беренче хәбәрчеләреннән.

---

[1] Ике юлның мәгънәсе:
Аннан үзен яклауны тели, –
Җаны белән аның гадәтләрен тота.

[2] Китапта: «буеңны».

[3] Ярдәме һәм юмартлык итеп.

[4] Юлның мәгънәсе: иреннәрең – якут, тешләрең – чәчкә бөресе, төймәсе.

[5] Кямаләти – төгәллеге.

Әтел суы ака торур,
Кыйа төби кака торур,
Балык тәлим бака торур, –
Күлүң тәкый кушәрүр[1].
[Кашгари, 1960, I, с. 103]

Бу шигъри форма Идел буе болгар-төркиләрдә аларның «имди» белән язылган «Авык кыйссасы» һәм «Кыйссаи Йосыф» әсәрләре иҗат ителгәнчегә кадәр үк киң урын алган була. Сөләйман Саксини дастаннарын, халык авыз иҗаты әсәрләрен, «Авык» кыйссаларын эченә алган болгар поэзиясе җирлегендә мең яшьлек имән кебек аның өскә калыккан классик үрнәге – Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы. Үзеннән алда бай поэзия җирлеге, шигърият практикасы булмаса, «Йосыф китабы» кебек югары сәнгать әсәрләре тумас та иде. Нәкъ менә шушындый хәлне күз алдында тотып, Белинский болай язды: «Поэзиянең шулай ук үзенең яше бар, ул һәрвакыт халыкның яшенә тиң» [Белинский, с. 10]. Моннан берничә еллар элек, «Дастане Могҗизат», «Авык кыйссасы» кебек әсәрләр әдәбиятыбызга әле билгеле булмаган вакытта, әдәбиятчы Р. Бикмөхәммәтов: «Гали бу гүзәл поэмасыннан («Йосыф китабы»ннан) тыш та бик күп әсәрләр язгандыр һәм без белмәгән күп кенә татар (болгар) шагыйрьләренең әдәби тәҗрибәләренә таянгандыр дип уйларга кирәк. Поэманың әдәби теле, поэтик синтаксисының чын сәнгатьчә югарылыгы әле Галигә кадәр үк җитлеккән әдәби традицияләрнең булуын раслый», – дип язуында хаклы иде [Бикмөхәммәт, б. 36].

«Дастане Могҗизат» үзеннән соңгы күп әдипләргә рух биреп, аларга үрнәк булып торган. Хикәятләрдән берсендәге:

Башлайалем кирү бер сүз сүзилә,
Уд сачсун бу сүземдән сүзилә, –

дигән бәет бөтен тышкы формасы һәм сүзләре белән соңыннан «Кисекбаш» дастанына килеп керә. Унбер иҗекле рәмәл үлчәвендәге ике юллы бәет татар поэзиясендә озын тарих буенча килә. Гариб Болгари, Хисам Кәтиб, Мөхәммәдьяр, М. Колый (Меллагол), Утыз-Имәни, хәтта Тукайдан соңгы шагыйрьләр дә шул шигъри үлчәүдә яздылар, ә лексикаларының нигезендә шул ук сүзләр булды. Мәсәлән, Сөләйман Саксинида:

Һәрки гакыйлдыр сүземни аңлар ул,
Һәм гакылсыз кем сүземни таңлар ул.

Мөхәммәдьярда:

Укыган гакыйль кешеләр аңлагай,
Бу зәгыйфь бичарә колына таңлагай.
(«Нуры-Содур»)

[1] Соңгы ике юлның мәгънәсе:
Балык күпләп карый тора,
Күле кушәрелеп – җәйрәп ята.

Сөләйман Саксинида:

Бонларә чук дерлү нәсыйх[1] әйләди,
Халкый[2] лотфилә[3] йанлари[4] туйлады.

Утыз-Имәнидә:

Безгә вирдең бер китап, хуб әйләдең,
Йахшы сүзлә күңлемезни туйладың.

Мондый мисалларны тагын да китереп булыр иде. Аның болары да төрле заманнарда яшәгән татар шагыйрьләре иҗатларының, алар әсәрләрендәге тел чараларының уртаклыгы, бер үк поэзиянең традицияләре хакында сөйлиләр. Идел буенда Болгар җирлегендә иҗат ителеп, бөтен Урта гасырлар болгар-татар поэзиясенә зур йогынты ясаган, шагыйрьләргә үрнәк булып торган «Дастане Могҗизат» күп дәверләр буена укучыларның эстетик сорауларына хезмәт итеп килгән һәм халыкның зур ихтирамы аны буыннардан буыннарга тапшырып, безнең көннәргә китереп җиткергән.

**Кайбер сөземтәләр**

Җыеп әйткәндә, Сөләйман бине Дауд Саксининың күркәм әдәби тасвир сыйфатлары белән тезелгән «Дастане Могҗизат»ы, һичшиксез, Идел буендагы шул заман болгар чоры әдәбиятының күренекле әсәрләреннән берсе булырга тиеш.

Соңгы вакытларда табылган яңа археологик материаллар Казан галимнәренә Идел-Кама болгарларының элгәрләре белән бәйләнешле аерым мәсьәләләрне хәл итәргә юл ачкан кебек [Генинг, Халиков, 1964; Халиков, 1966], Сөләйман Саксини әсәрләре дә шул заманда Болгар дәүләте ирешкән культура, әдәбият, философия, әхлак-мораль, фикъһе-юриспруденция фәннәре турында яңача фикер йөртеп, аларны яңача бәяләргә нигез бирә. Сөләйман бине Дауднының зур поэтик әсәре булган «Дастане Могҗизат» борынгы Идел буе төрки әдәбияты, ягъни болгар-татар әдәбияты турындагы төшенчәне тагын да киңәйтә һәм Галинең «Йосыф китабы» кебек әсәрләрне яхшырак төшенергә, ныклабрак өйрәнергә юл ача, аларның болгар-татар әдәбияты әсәрләре икәнлеген бәхәссез ясый.

Сөләйман әсәрләренең теле – кыпчакча тел, анда көньяк төркиләре, угыз элементларының урын алуы гаҗәп түгел. М. Кашгари угыз, кыпчак, бәҗәнәк, ямәк, суварийн, болгарларның бер географик киңлектә аралашып яшәгәнлекләре хакында сөйли, аларның телләрендәге үзенчәлекләрне дә күрсәтә [Кашгари, 1960, I, с. 68; II, с. 53]. Ибне Фадлан Болгарга килгән вакытта, болгар халкы Алмасның хатыны угыз ханнарыннан берсенең кызы булганлыкны, Болгарда Харә-

[1] Нәсыйх – киңәш итү.
[2] Халкый – халыкны.
[3] Лотфилә – шәфкатьлеге белән.
[4] Йанлари – әйләнә-тирәдәгеләрне.

зем төрекләренең яшәгәнлекләрен әйтеп уза [Ковалевский, с. 129–140 (перевод), 202б–209а (текст)]. Әбүл-Гази да кыпчакларның Дон, Идел һәм Җаек елгалары арасындагы урыннарда яшәгәнлекләрен сөйли [Родословное..., с. 34]. Чиктәш угыз кабиләләре, Харәзем төрекләре белән тыгыз сәүдә, экономик һәм культура мөнәсәбәтләрендә булу, хәтта кыз бирешеп, кыз ярәшеп, ыруг-кардәшлек бәйләнешләрендә яшәү Идел буе төрки теленә тәэсирсез калмаска тиеш иде. Болгар илендә язылган әсәрләрнең телендә көньяк төркисе – угыз элементларының булуы да үткәндәге шул социаль тарихи шартлар белән бәйле. Урта гасырлар болгар-татар әдәбиятының нигезен тәшкил иткән Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы кебек әсәрләрнең телләрендә угыз элементлары булганлыктан, кайберәүләр тарафыннан болгар-татарныкы итеп танымаска тырышуларның да сәбәбе әле генә саналган шартлар белән исәпләшмәүдән, Идел буенда монголларга кадәр барлыкка килгән әдәбият мирасын якыннан өйрәнмәүдән һәм әдәбиятны тудыручы соңыннан татар исеме белән аталган болгар-кыпчак төрекләренең тарихи язмышы белән бәйләп карамаудан иде. Шунлыктан, Болгар дәүләтендә XII йөзнең урталарында ук формалашкан Идел буе әдәби теле танылмады, ә Сырдәрьяның түбән агымы буендагы культура үзәкләрендә барлыкка килгән Әхмәт Ясәви теленең таралу мәйданы артык киңәйтеп күрсәтелде. Хәтта XIV йөздә Алтын Урда заманында Урта Идел, Урал буйларында формалашкан әдәби телнең дә нигезе итеп Харәземнән килгән тел саналды. Мәсәлән, Әмир Нәҗип болай язды: Әхмәт Ясәви «хикмәтләре язылу белән XII йөздә төрки халыкларның икенче бер әдәби теле – угыз-кыпчак телләре нигезендәге әдәби тел барлыкка килә. Соңга таба бу әдәби тел Харәземдә тагын да үсә, Алтын Урда дәүләте төзелеп, Харәзем шуңа кушылганнан соң, бу дәүләттә формалашкан әдәби телнең нигезе итеп менә шул тел алына» [Нәҗип, б. 93].

Әлбәттә, Ә. Нәҗип бу юлларны язганда – XII йөзләрдә Идел буе төрки әдәбиятының булганлыгын күрсәтүче «Дастане Могҗизат» кебек әсәрләр әдәбият белемендә әле телгә алынмыйлар иде.

Сөләйман Саксини әсәрләре күрсәткәнчә, XII йөзнең урталарында нәкъ Әхмәт Ясәвинең әсәрләре Сырдәрьяның түбән агымында иҗат ителгән вакытларда, Болгар дәүләтендә, ягъни Иделнең урта агымыннан алып, Каспийга кадәр җәелгән аралыкта, Әхмәт Ясәви хикмәтләреннән һәм аларның теленнән башка, мөстәкыйль бер әдәбият һәм әдәби тел барлыкка килә. Бу үзенең теле, стиле – өслүбе белән генә түгел, идея-эчтәлеге белән дә Әхмәт Ясәвинең динимистика, суфичылык идеяләре белән сугарылган хикмәтләреннән башка юнәлештәге, дөньяви характердагы әдәбият һәм поэзия була. Ул – болгар галиме, әдибе һәм шагыйре Сөләйман бине Дауд Саксини Сувари әсәрләре һәм аларның теле. Бу – угыз-кыпчак теле түгел, ә, Н.А. Баскаков сүзләре белән әйткәндә, «болгар һәм кыпчак ыру телләренең үзара бәйләнеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән» [Баскаков, с. 160] болгар-кыпчак (борынгы татар) теле. Идел буенда монголлар

килгәнчегә кадәр формалашкан җирле әдәби тел – шул тел була. Җ. Алмаз фикеренчә, Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре дә нәкъ шул әдәби телдә язылган [Алмаз, 1960].

Монгол яулап алучылары килгәч, Идел буендагы бердәнбер культура үзәкләреннән булган Болгар шәһәрләре җимерелә, халкы буйсындырылып, дистәләрчә галимнәре, язучылары һәлак ителә, иҗат эшчәнлеге, әдәбият һәм әдәби тел үсеше тоткарлана. Ләкин соңга таба, яулап алучылар, үзләрен әйләндереп алган күпсанлы җирле болгар-кыпчаклар тәэсиренә бирелеп, аларның диннәрен дә кабул иткәч, җирле халыкның телен дәүләт теле итеп танырга мәҗбүр булалар. Шул хәлдә, яңа тарихи шартларда элекке Идел буе төрки әдәби теле яңадан җанланып китә, яңа әсәрләр иҗат ителә башлый. Бу – Алтын Урда ханнарының теләве белән түгел, тарих процессының таләбе белән була. Бу – Болгар дәверендә XII йөзнең урталарында формалашкан әдәби тел үсешендәге икенче этап булып тора. М. Сәфәргалиевнең исә хәзерге татар теленең тарихын кыпчак теленең Алтын Урда дәвере белән генә чикләп каравы һич тә дөреслекне чагылдырмый [Сафаргалиев, с. 36]. Чыннан да, Алтын Урда дәүләте үзәге булган Иделдә XIV йөз урталарында формалашкан әдәби тел кайдандыр Харәземнән китерелгән тел түгел; әйткәнебезчә, ул – Идел буендагы күпсанлы җирле төрки халыкларның, болгар-кыпчакларның җанлы сөйләм теле нигезендә иkенче социаль шартларда алга таба үсеп киткән тел. Татар теленең формалаша башлавын болгар чорыннан аерып алу мөмкин түгел. Вахит Хаков: «Үзенең локаль үзенчәлекләре белән татар әдәби теле X–XIV йөзләрдә Урта Идел һәм Кама буйларында формалаша» [Хаков, б. 33], – дип язуы белән, мәсьәләгә дөрес якын килә. Чөнки «яңа дәүләт составына кергәч тә, Болгар Алтын Урда культурасын үз тирәсендә формааштыручы үзәк булып торган» [Смирнов, с. 74]. Үзенең шундый югары культурасы, әдәбияты булган һәм Алтын Урта дәүләтенең төп халкын тәшкил иткән кыпчакларның әдәби теле мистик Әхмәт Ясәви хикмәтләре теленнән килә дип билгеләргә тырышу җәмгыятьнең үсеш законнарына туры килми. Монда икенче бер нәрсәне генә онытырга ярамый. Ул да булса, битикче – язучы уйгурларның да, шунда яшәгән харәзм төрекләренең дә ул әдәби телгә йогынтысы көчле булган. XIV йөзләрдән алып, Идел буенда болгар-татар телендә иҗат ителгән әсәрләр лексикасында уйгур элементларының киң урын алуының да сәбәбе шул хәл белән аңлатылырга тиеш.

Борынгы Идел буе төрки әдәбияты вәкиле Сөләйман Саксинига багышланган бу хезмәт хәзергә беренче тәҗрибә буларак каралырга тиеш. Киләчәктә шагыйрьнең башка әсрәләре яисә аның үзе турында яңа материаллар табылуы мөмкин; андый хәлдә бу талант иясенең иҗатын тагын да ныклабрак өйрәнергә булыр. Ләкин, бәхет йолдызы киләчәктәниләр генә китермәсен, Сөләйман бине Дауд Саксини-Сувари һәм аның «Дастане Могҗизат» әсәре болгар-татар әдәбияты

тарихында лаеклы урынны алыр һәм аңа тиешле бәя дә бирелер дип өмет итәргә кирәк, чөнки чын сәнгать әсәрләре үлүне белмиләр.

8.05.1969

**Әдәбият**

*Алмаз Җ.* Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. 1960. № 2.

*Бартольд В.В.* Сочинения. М.: Изд-во вост. лит., 1963, т. 2, часть 1, 710 (место прикаспийских областей в истории мусульманского мира).

*Баскаков Н. А.* Тюркские языки / отв. ред. Г.Д. Санжеев; Институт языкознания АН СССР. М.: Изд-во вост. лит., 1960. 248 с.

*Белинский В.Г.* Избранное. М.: Московский рабочий, 1954.

*Бикмөхәммәт Р.* Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре (традицион образларны өйрәнү тәҗрибәсеннән). Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Валитова А.* К вопросу о фольклорных мотивах в Кутадгу билик // Советское востоковедение. 1958. № 5.

*Генинг В.Ф., Халиков А.Х.* Ранние болгары на Волге (Больше-Тарханский могильник). М., 1964.

*Греков Б.Д.* Избранные труды, т. 2, изд. АН, М., 1959, 569 (Волжские болгары в IX–X вв.).

*Заходер Б.Н.* Каспийский свод сведений о Восточной Европе (Горган и Поволжье в IX–X вв.). М.: Изд-во вост. лит., 1962, 144 бит.

*Карамзин Н.М.* История государства Российского. Т. 3, изд. второе, исправ. СПб., 1818.

*Кашгари М.* Диван лөгатет-төрк. 2. Истанбул, 1338/1915, 70 б.

*Кашгари М.* Диван. I. 68; II, 53 (Ташкент).

*Кашгари М.* Диван. Ташкент, 1960. I, 103.

*Ковалевский А. П.* Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков, 1956.

*Лихачев Д.С.* Человек в литературе Древней Руси М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1958.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951.

*Маркс К.* «Политик экономияне тәнкыйть итүгә карата»га сүз башы // Маркс К., Энгельс Ф. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Т. 1. Казан, 1949.

*Маркс К., Энгельс Ф.* Манифест Коммунистической партии. Госполитиздат, 1952.

*Маркс К.* Тезисы о Фейербахе (Ф. Энгельс. Людвиг Фейербах и конец классической немецкой философии. Госполитиздат, 1952.

*Маркс К.* К критике политической экономии. Госполитиздат, 1951.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области // МТД, 2, Казань, 1962.

*Махмутова Л.Т.* Фонетические особенности касимовского говора татарского языка // МД, Таткнигоиздат, 1955.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфад әл-Ахбар.... 1. Казан, 1897.

*Нәҗип Әмир.* XIV йөз шагыйре Сәйф Сараи һәм аның заманы // Совет әдәбияты. 1957. № 4. Б. 93.

*Плано Карпини.* История монголов / под ред. Н.П. Шастиной, ГИГЛ. М., 1957.

ПСРЛ, т. 1, Лаврентьевская летопись (вып. 2 Суздальская летопись по Лаврентьевскому списку). Изд. второе. Л., 1927.

Родословное древо тюрков / соч. Абуль-Гази, Хивинского хана; перевод и предисловие Г.С. Саблукова. Казань: Тип. импер. ун-та, 1906.

*Рясянен М.* Материалы по исторической фонетике тюркских языков / перевод с немец. А.А. Юлдашева. М.: ИЛ., 1955.

*Сафаргалиев М.Г.* Распад Золотой Орды. Саранск: Мордва книгоиздат., 1960.

*Смирнов А.П.* Древняя история чувашского народа. Чебоксары: Чувашгосиздат, 1948.

*Тенишев Э.Р.* «Материалы по татарской диалектологии» (рец.) // Вопросы диалектологии тюркских языков. Т. IV. Изд-во АН АзССР, Баку, 1966. Б. 216–220.

Ф. Людвиг Фейербах и конец классической немецкой философии. Госполитиздат, 1952.

*Хаҗи Хәлфә.* Лексикон. Т. 2, 3.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле буенча очерклар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965.

*Халиков А.Х.* Среднее Поволжье в эпоху камня и бронзы: автореф. дис. ... д-ра ист. наук. Казань, 1966.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу Али Ахмеда бен Омара Ибн-Даста. СПб., 1869.

*Хлебникова Т.А.* Основные производства волжских болгар периода X – начала XIII в.: автореф. дис. ... канд. ист. наук. 1964. 25 с.

*Шамгунова Р.* Чистай сөйләшенең морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре // МТД, 2.

*Текстны басмага әзерләде:*
***Әлфрид Кашаф улы Бостанов,***
*Ph.D., Амстердам университеты ассистент-профессоры*